www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 36 (1452) 15 сентябрь 2023 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga



6

Плётцензее төрмәсендә газаплап үтерелгән 11 татар каһарманы арасыннан бер Муса Җәлилне генә күтәрделәр дә, Абдулла Алиш, Гайнан Кормашлар күләгәдә калды.

12-13

Сынчы Алинә Маликова 28 яшьтә генә булса да, ул инде Ржев каласы янында сугышып һәлак булган совет солдатларына багышланган гүзәл һәйкәлне иҗат итүдә дә катнашты.



16-17

1812 елгы Ватан сугышы ветераны Гали Мәхмүдов Казан университетында шәрык телләрен генә түгел, студентларга каллиграфик язу нечкәлекләрен дә укытып дан алган.

Бәрәңге дә милли байлык безнең, Ил-халыкны ул да саклаган!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Теләче районының Иске Җөри авылында узган Таһир Якупов исемендәге I республика фестивалендә 20 дән артык җырчы лауреат исеменә, ә 37 ел буе гражданнар авиациясендә очучы булып эшләгән Әхтәм Җамалиев Гран-прига лаек булды.

● Воронеж өлкәсендәге Борисоглебское шәһәрендә үткән бер туй барышында кунаклар урамга чыгып күмәкләшеп сугышырга тотынгач, полиция хезмәткәрләре урамдагы машиналар хәрәкәтен ябып куярга мәҗбүр булган.

● Башкортстандагы Мәләвез районының Нугуш авылы янында урманнан чыккан бер аюның сыерга һөҗүм итүен күреп, машинада узып баручы Ринат исемле егет әүвәл сигналга басып кычкырта, аннары кычкыра-кычкыра күсәк ыргыта, нәтиҗәдә аю куркудан янә урманга кереп кача.

● Байкал арьягы краеның Таулы Зерентуй авылында чыккан янгын нәтиҗәсендә ике фатирлы бер йортта ире, хатыны һәм ике бала янып үлгән.

● Мароккода җир тетрәү корбаннарының саны 1050 кешегә җиткән, 1200дән артык кеше яраланган.

● Киров өлкәсенең Малмыж районындагы Иске Йөрек авылында янгын чыгу сәбәпле, өч балалы Ягафаровлар гаиләсе урамда калган.

● Тыва республикасының Олы Хелск районында «Авиалесохрана» оешмасының «Вепрь» машинасында эшләүче бер шофер руль артына исерек хәлдә утыра һәм «Хонда» машинасына бәрелеп, анда тулы бер гаилә – биш кешене һәлак итә.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

16 сентябрь – 1917 елда Казан Кремлендә Сөембикә манарасы очындагы бөркет ярымай белән алыштырыла.

17 сентябрь – Россиядә хатын-кызлардан беренче офицер, язучы Надежда Андреевна Дурованың тууына 240 ел (1783–1866);

– тел галиме, филология фәннәре докторы Дәрия Бәйрәм кызы Рамазанованың тууына 85 ел (1938-2019).

19 сентябрь – әдәби тәрҗемәче, язучы Гөлсем (Өммегөлсем) Даут кызы Мөхәммәдованың тууына 120 ел (1903–1988);

– композитор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Луиза Әхмәтҗан кызы Хәйретдинова 75 яшь (1948).

СЫНАМЫШЛАР

● 15 сентябрьдә җылы булса, көз буе җылы була ● Сентябрьдә кар күренсә, көз озакка сузыла ● Агач яфракны соң койса, ел авыр килә ● Көз көне кошлар түбән очса – кыш салкын, югары очса – җылы килә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 15 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 05 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **12 сәгать 50 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **22 сентябрьдә 12 сәгать 18 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Сентябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(15-22 сентябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген сәфәр аеның 30 нчы көне

КӨН КАДАГЫ

ҖИЛӘК САТУДАН 150 МЕҢ

Чүпрәле районы Иске Кәкерле авылында Җәләлетдиновлар гаиләсе 10 елга якын җиләк үстерү белән шөгыльләнә. Пекарня бизнесы белән килеп чыкмаса да, бүгенге көндә җиләк җыю – аларның яраткан һәм табышлы гамәле.

Әлфәт абый белән Рәмзия апа икесе дә Чүпрәле районында туып үскән. Аларны Казанда уртак дуслары таныштырган. Ул вакытта Әлфәт абый КСЮИда (хәзерге АСО) юристлыкка укып чыгып эшли, ә Рәмзия апа КГПУда математика факультетында укытучылыкка укый торган була. 2009 елның июнендә Рәмзия апа диплом алгач, Әлфәт аңа тәкъдим ясый, һәм шул елның көзендә аларның туйлары була.

Яшь гаилә 3 ай Казанда торып карагач, шәһәр тормышыннан туеп, Чүпрәле районындагы Иске Кәкерле авылына әйләнеп кайталар. Бу карар аларның уртак хыялларын тормышка ашыруга таба илткән беренче адымнары була. Авылда яшьләр үз теләгенә ирешә. Аларга «лизинг грант» программасы буенча 600 мең сум акча бирелә. Әлфәт абый бүлеп бирелгән акчага Казаннан УАЗ машинасы, ә Рәмзия апа пекарня өчен кирәкле җиһазларны сатып ала. Шушы көннән алып алар үзләренең эшләрен башлап җибәрә. Кыш көне пекарня өчен фундамент салынса, икенче елның җәендә ул төзелеп тә бетә. Рәмзия апаның хәтта ипине пешерә башлаган көннәре дә исендә калган:

– 2010 елның 31 октябрендә беренче ипиләрне сала башладык, аннары төрле пироглар, камыр ризыклары пешереп, авылдагы төрле кибетләргә тараттык. Халык пирогларны бик ярата иде, бер бәйрәм дә безнең пешергән ризыклардан башка үтми иде, кайсы вакытта сагынып та куям ул чакларны, – ди Рәмзия апа.

Өйләрендә пешереп сатучыларның күбәеп китүе, Рәмзия апаның үз һөнәре буенча эшкә керүе, пекарняга оста пешекчеләрнең җитмәве 2017 елда аның ябылуына сәбәп була. Шулай да, бер ишекнең ябылуы икенчесенең ачылуына китерә. Алар җиләк үстереп сата башлый.

Әлфәт абыйның җиләк үстерү белән кызыксынуы реклама журналында урнаштырылган җиләк фотосыннан башланып китә. Ул әлеге фирмадан нәкъ менә фотога төшерелгән «Гигантелла» сортын заказ биреп, аны почта аша кайтарта. Аларны үстереп, татып карагач, шундый тәмле җиләк тә була икән дип, ул аларны күбрәк урынга күчереп утырта. Шунысы кызык, бу 2008 елда була. Шулай итеп, Әлфәт абый ел саен диярлек яңа сортларны кайтартып, аларны «сынап» карый. Әгәр дә алар чыннан да тәмле һәм чыдам икән, ул аларны үзендә калдыра. Иң беренче, ул Займище питомнигыннан 35 меңгә 1000 төрле үсенте барып ала. Ул уңышлы булып чыга, тик тәҗрибәсезлек аркасында күп югалтулар була. 5 ел дәвамында ул үзенчә «экспериментлар» ясый. Шулай итеп, бер кызыксыну эшмәкәрлеккә әйләнә дә куя. Әлфәт абыйның бизнес оештыру теләген тормыш иптәше Рәмзия апа да хуплый.

– Мин Әлфәтнең фикерләрен, идеяләрен һәрвакыт хуплыйм. «Эшлим, булдырам!» дип торган кешегә ничек булышмыйсың инде. Ул бит җаваплылыкны үз өстенә ала: җиләкләрне яхшылап карап тора, эшен яратып эшли. Икенче берәү булса, эшне әллә кайчан ташлаган булыр иде, – ди Рәмзия апа.

Беренче вакытта аларга әтиәниләре дә бик нык ярдәм иткән, хәзер дә хәлләреннән килгәнчә булышып торалар.

2015 елда гаилә күпләп уңыш ала башлый. Үзләре бер шатланса, балалары тагын да катырак сөенә. «Улларыгыз җиләкне бик яратып ашагандыр инде», – дигәч, «Алар түгел, үзебез дә әлеге вакытта да җиләк ашаудан туймыйбыз әле», – дип көлеп җавап кайтарды Рәмзия апа.

Шулай итеп, алар җиләкне туганнарына, якын-тирә күршеләренә әкрен генә сата башлый. Иң беренче сатып алучылары Әлфәт абыйның туганнан туган апасы Алсу була. Ул җиләкне 5 меңгә сатып алып китә. Халыкка ошый, алучылар һичшиксез булачак дип, шундук сөенеп куя алар. Сөенүләре юкка гына булмаган, бүгенге көндә алар үстергән җиләкләрне Иске Кәкерле авылы халкы гына түгел, күрше Чувашия һәм Ульяновск өлкәсеннән дә махсус килеп алалар. Аларның 40 сутый җирләрендә 20 мең төптән артык җиләкләре бар. Сортлары да 15 тән артып китә. Арада бик «капризныйлары» да бар икән.

– Һәр сортның үзенә генә хас холкы була. Мисал өчен, «Элиания» сорты бик тәмле, ләкин кышны ул бик авыр чыга. «Витязь» сорты тәмле түгел, ә «Берегиня» еш авырый. «Полька» дигән сортның тәме җир җиләгенеке кебек. Иң тәмлесе – беренче алган сортым «Гигантелла», ләкин аны да карап торырга кирәк, – ди Әлфәт абый.

Белгәнебезчә, эшмәкәрлекнең ике ягы бар. Беренчесе – керем, икенчесе, кеше күзенә бик үк күренмәгәне – тырышлык. Эшмәкәрләр әйтүенчә, җәйге сезонда 100 мең сумнан артык чыгым китә, 1 ай эчендә 150 меңнән артык чиста керем килә. Тик моны әле эшләп таба белергә дә кирәк. Яшь эшмәкәр үзе дә җиләк үстерүнең уңай һәм тискәре якларын санап үтте. Аның уңай яклары: халыктан сорау бар, тәмле һәм файдалы җимеш, сортларның күп булуы. Тискәре яклары: бик игътибарлы карауны таләп итә, моның өчен тәҗрибәле булу кирәк, уңыш алу һава шартларына бәйле, сортларны һәрвакыт яңартып тору сорала.

– Аны һәрвакыт авырулардан, бөҗәкләрдән саклап торырга кирәк. Әгәр дә җиләк еш авырый икән, димәк, ул баштан ук дөрес утыртылмаган. Җиләкне иркен (арасы ким дигәндә 30 см, ә рәт арасы 40 см), һава һәм кояш керерлек итеп утыртырга кирәк. Шулай ук эшебездә Фитоспорин, Вертемек, Аполло кебек биопрепаратлар ярдәмгә килә. Су сибүгә килгәндә, иң әйбәте – «капельный полив», чөнки су яфракка һәм җиләккә тиярргә тиеш түгел. Җиләк төпләре өчен артык дым да, коры да ярамый, суны төпләрен кул белән тикшереп карап сибәргә кирәк. Җылы су сибү, әлбәттә, яхшырак, – ди эшмәкәр.

Һичшиксез, җиләкнең булу-булмавы һава шартларына бәйле. Мисал өчен, бу елны 7-10 май көннәрендә бик салкын булган. Шуңа бәйле, җиләкнең беренче чәчәкләре зыян күргән. Өстән су сибеп, саклап калырга теләсәләр дә, килеп чыкмаган. Мондый хәл кабатланмасын өчен, киләсе елга алар туннель ысулы белән җиләк өстенә пленка капларга уйлыйлар. Туфракның каты, авыр булуы сәбәпле, җиләкнең мыекларын да хәзер җиргә түгел, ә махсус торфка утырталар. Болай җиләк җиңелрәк тамыр ала икән.

Бернчә елдан бирле гаилә җәй көннәрендә авылның олыларын-яшьләрен эш белән тәэмин итеп тора, кешенең эшләргә теләге генә булсын! Билгеле сәбәпләр аркасында, бу елны җиләкне гаиләләре белән генә җыйганнар. Ә киләсе елга уңыш әйбәт булса, җиләк җыючылар аларга тагын кирәк булачак. Иртәнге сәгать 8:00дән алып 16:00гә кадәр 1500 сум яисә күбрәк тә акча эшләп була икән.

Бу елны 1 кг җиләк 270 сумнан сатылган. «Бәясе җиләкнең күп булу-булмавына бәйле түгел, икенче елга да шул ук булачак», – дип әйттеләр.

Җиләк үстерүдән кала нинди эшмәкәрлек белән шөгыльләнер идегез, дигән сорауга эшмәкәрләрнең икесе ике төрле җавап бирде. Әлфәт абый сарымсак яки кура җиләге үстерергә теләсә, Рәмзия апаның тотрыклы эштә эшлисе килә икән. Ул авылда эшнең, балалар бакчасында баларның бетмәвен, яшьләрнең авылга кайтып торуларын тели.

Эшмәкәрләр әйтүенчә, Чүпрәледә конкуренция көчле. Тик алар аның булуын яхшы дип саный.

– Район күләмендә органик ашлама кулланып үстерүчеләр юк. Ә кырда, сәнгать күләмендә, Дуван авылы һәм Түбән Чәкедә «АгроТранпорт» компанияләре җиләк үстерә, – ди Әлфәт абый.

Алар конкуренциядән курыкмый, чөнки халык аларның эшен бәяли, күрә белә. Безгә иң зур мотивация бирүче дә – халык, ди алар. Чыннан да, Әлфәт абый да, Рәмзия апа да үз эшләренә җаннары-тәннәре белән бирелеп эшли. Алар өчен бәхет – исән-сау булып, яраткан эш белән шөгыльләнеп, тормышта үз-үзеңне табу.

Раилә ФӘХРЕТДИНОВА.
Интертат.

Җырчы истәлегенә фестиваль

Теләче районының Иске Җөри авылы мәдәният йортында «Карачтау авылы көйләре» дип аталган татар җырын башкаручылар фестиваленең йомгаклау концерты узды. Халкыбызның сөекле җырчысы Таһир Якуповка багышланган әлеге фестиваль быел беренче тапкыр үтте. Егерме биш һәвәскәр җырчының чыгышын залдагы тамашачы йотлыгып тыңлады. Без чын мәгънәсендә халык иҗаты бәйрәмен оештыручыларның продюсеры Җәүдәт Гыйлманов белән әңгәмә корып алдык.

– Җәүдәт әфәнде, ни өчен танылган җырчыга багышланган фестиваль Иске Җөридә узды?

– Берничә ел элек Теләче районы Камал театры бинасында үзенең юбилей концертын уздырды. Әтием Теләченеке булгач, мине дә чакырдылар. Шул бәйрәмдә Таһир Якуповка багышланган стендка күзем төште. Район хакиме Айрат әфәнде аның якташыбыз икәнен әйтте. Үткән ел туганнарга кунакка кайткач, Иске Җөри мәдәният йорты җитәкчесе Равил Насыйбуллин белән очрашып, фестивальне оештыру турындагы ниятемне әйттем. Шул ук көнне «Китап» радиосының баш мөхәррире Алмаз Миргаязов белән дә сөйләштек. Теләче кияве бит, ул бәйгене рекламалауны үз өстенә алды. Апрель башында бәйгене игълан да иттек.

– Гаризалар күп килдеме?

– Бер ай эчендә нибары бер гариза килде. Ә бервакыт гаризалар агымы кузгалды! Катнашучылар бер Таһир Якупов репертуарындагы җырны, бер үзләре теләгән җырны видеога яздырып җибәрергә тиеш иде. 132 гариза килде. Татарстаннан тыш, Башкортстан, Удмуртия, Киров өлкәсе, Мари, Чуаш республикаларыннан да катнаштылар. Баштан ук бәйгедә һәвәскәр җырчылар күбрәк катнашыр дип уйладык. Халык арасындагы матур тавышлы җырчыларны барларга теләдек. Шулай булып чыкты да: катнашучыларның 95%ы һәвәскәрләр. Халыкта талантлар күп. Катнашучыларның күпчелеге өлкән яшьтәгеләр булу исә уйландыра. Бүгенге яшьләрнең кайберләре Таһир Якуповның кем икәнен дә белми… Атаклы җырчының исеме онытылып бара, шул кызганыч. Соңгы елларда радио, телевидениедә аның турында бөтенләй телгә алган кеше булмады. Шушы хәлгә йөрәк әрнегәнгә, без бу эшкә алындык.

– Талантларны сайлау кыен булмадымы?

– Миңгол абый Галиев җитәкчелегендәге жюри 132 кешедән 42 сен сайлап алды. Жюрида Зөфәр Хәйретдинов, оештыручылар да бар иде. Аннары шул 42 арасыннан яхшыларын сайлап, 2 нче турга чыгардык. 2 сентябрьдә аларны тыңлау башланды. Ә кичен лауреатлар гала-концертта чыгыш ясады. Зал шыгрым тулы, Казаннан да шактый кунак кайтты. Тамашачы бәйгедә катнашучыларны җылы кабул итте. Күпчелек җырлар баянга җырланды. Артистлар яхшы белә, баян белән тамашачыны тотып тору җиңел түгел. Концерт тәмамлангач та, тамашачылар озаклап алкышлады, рәхмәт әйтте.

– Күңелегезне аеруча кемнәр яулады?

– Бик матур тавышлы җырчылар күп иде. Берсен генә әйтәм. Баштан без Гран-при бирербез дип уйламаган да идек. Ләкин сәхнәгә Әхтәм Җәләлиев чыккач, фикеребез үзгәрде, жюри бердәм төстә аңа Гран-при тапшырырга булды. Ул инде өлкән кеше, тумышы белән Чирмешәннән, 37 ел очучы булып эшләгән, гомере буе җырларга яраткан, ә зур сәхнәгә чыгып җырлавы беренче тапкыр икән.

– Лауреатлар нинди бүләккә ия булды?

– Барлык җиңүчеләр дә «Риф-Рекордс» студиясендә җыр яздырырга сертификат белән бүләкләнде. Студия җитәкчеләренә бу бүләк өчен рәхмәт. Киләчәктә бәйгедә җиңүче җырлар «Китап» радиосы аша да яңгырар, дип уйлыйбыз. Гомумән, бу олы җырчыбызның исемен, җырларын онытмас өчен оештырылган чарага ярдәм кулын сузган һәркемгә рәхмәт. Җырчылар Резедә Шәрәфиева, Наилә Славина, режиссер Азат Зарипов, шагыйрә, алып баручы Гөлинә Шәйхи, Миңгол абый Вәлиев, Зөфәр Хәйретдинов һ.б. барысы да Таһир абыйның истәлеге хакына энтузиазм белән эшләде.

– Аның исемен онытмас өчен тагын ниләр эшләп була?

– Таһир Якуповларның төп нигезләре Карачтауда, ул Иске Җөригә күрше авыл, бер авыл җирлегенә керәләр. Җырчының нигезенә бер истәлек стеласы куйдырырга иде. Башта андагы агачларны кисеп, нигезне тәртипкә китерергә кирәк. Фестивальне дә ел саен үткәрәсе иде. Бераз аякка баскач, фестиваль җиңүчеләрен Казан сәхнәсенә дә чыгару нияте бар. Тиздән Таһир Якуповның тууына 80 ел тула. Аның исемен Казанның бер урамына бирдерүне хәл итәсе иде. Чын мәгънәсендә халык җырчысы булган моң чишмәбезнең исемен онытсак, без кем булабыз инде?..

Әңгәмәдәш –
Эльмира СИРАҖИ.

«ДәртФест» фестиваленә 40 мең кеше килгән

Казан Кремлендә узган «ДәртФест» заманча татар мәдәнияте фестивален 40 000нән артык кеше тамаша кылган. «17.00 сәгатькә металл тикшергечләр аша 30 меңнән артык кеше узган иде инде», – диде оештыручыларның берсе, музыкаль продюсер Ильяс Гафаров. Бу – зур сан. Әйтик, 2019 елда гына 40 меңгә якын кеше килгән булган. Башка елларда бу сан әзрәк.

Фестивальнең музыкаль өлеше төп ике сәхнәдә барды. Гавәми урынкарда төзелгән сәхнәдә Juna фолк-төркеме, Gauga рок-төркеме, Yummy Music Band төркеменең «Илһамга мәдхия» проекты кысаларында Илгиз Шәйхразиев, Эльвира Мифтахова, Эльза Заяри, Артур Исламов һәм Алинә Шәрипҗанова, ә Туп сарае ишегалдында Лилиана Газизова, Илшат Сафин, Марат Яруллин һ.б. чыгыш ясады.

Традицион милли товарлар ярминкәсе, китаплар ярминкәсе оештырылган иде. Балалар мәйданчыгы эшләде.

Фестивальнең бер яңалыгы – мода күрсәтү оештырылды.

Фестивальнең үзенчәлеге – төп оештыручы моңарчы Татарстан Мәдәният министрлыгы булса, хәзер Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә оештырылды.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.
Фото: Рамил ГАЛИ.

1 нче биттә – Татарстан кырларында бәрәңге алу тәмамланып килә.

Композитор бүләге



88 яшьлек композитор, Татарстан Республикасының халык артисты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әнвәр Шәрәфиев шушы көннәрдә халкына рухи бүләк ясады: Татарстан китап нәшриятында аның «Моң чишмәсе» исемле яңа китабы 1000 данә тираж белән басылып чыкты.

Китапка кереш сүзне РФ һәм ТР Композиторлар берлеге рәисе, Россия һәм Татарстанның халык артисты, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәшит Кәлимуллин язган. Шуннан бер өзек: «Уйнагыз, гармуннар!» җырын ишетмәгән кеше бик сирәктер. Бу җыр 1986 елдан башлап Казанда һәр ел саен уздырыла торган республикакүләм гармунчылар фестиваленең дә исеме булып тора, һәм ул Ә. Шәрәфиевкә республикада гына түгел, Россиядә, хәтта чит илләрдә дә танылу китерде.

Китапның музыкаль мөхәррире – күренекле композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, М. Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты Риф Гатауллин. Аның җыентыкка кертелгән язмасы китап исеме дә булып тора. 200 биттән арткан әлеге ноталы басмада балалар һәм хор өчен җырлар, камера һәм симфоник музыка, композиторның тормышы һәм иҗаты турында төрле елларда матбугат битләрендә дөнья күргән мәкаләләр, фоторәсемнәр туплап бирелгән.

Өлкән композитор яңа иҗат җимешен республикабыз Композиторлар берлегенә, «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» газеталары, «Сәхнә» журналы, «Тәртип» радиосы редакцияләренә, «Аксу» студиясенә, РФ Дәүләт Думасы депутаты Артем Прокофьевка, Сарманда яшәүче шагыйрь Дамир Гарифуллинга, Азнакай районы башлыгы Марсель Шәйдуллинга, авылдашлары – Урсай авыл советы депутаты, эшмәкәр Айрат Хафизовка, РФның гомуми белем бирү почётлы хезмәткәре булган укучысы Мәдинә Гариповаларга бүләк итеп өлгерде. «Миңа бәхетле картлык насыйп булды», – ди Әнвәр ага, шатлыгы белән уртаклашып. Сүз уңаеннан, композиторның туган авылы Урсай быел үзенең 325 еллык юбилеен билгеләп үтте.

Республикабызда игълан ителгән «2023 ел – милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы» программасы кысаларында 15 сентябрьдә башкалабыз Казанның В.И. Ленин исемендәге мәдәният сараенда Азнакай районы «Чатыртау кунак җыя» бәйрәмен үткәрә. Әнвәр ага Шәрәфиевның әле генә «табадан төшкән» өр-яңа китабы бу чараларда якташлары күңеленә хуш килер һәм бәйрәм әчтәлеген тагын да баетыр дип ышанасы килә.

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ,
китапны төзүче,
хезмәт ветераны.

Кырлайда «Ат көне» узды

9 сентябрьдә Арча муниципаль районында традицион ат-спорт бәйрәме – «Ат көне» узды. Бу хакта «Арча-информ» хәбәр итте.

Ат-спорт фестивале кысаларында татар атларында, чиста канлы һәм ярымкатнаш канлы атларда һәм җирле токым атларында 40, 80, 100, 120 һәм 160 чакрым дистанцияләрдә ат чабышлары, конкурслар, күргәзмәләр, кинологларның күрсәтмә чыгышлары, концерт һәм авыл хуҗалыгы ярминкәсе узды. Шулай ук «Ат арбасында иң тиз йөртүче», «Иң матур бизәлгән арба» номинацияләрендә җиңүчеләр ачыкланды.

Фестиваль Татарстан Республикасы өчен мөһим чараларның берсенә әверелде һәм ул бөтен ат индустриясенә ярдәм итүгә, аны үстерүгә һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән чараларның аерылгысыз өлеше булып тора.

Чара 2015 елдан башлап Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Атчылык һәм ат спорты федерациясе, «Татмелиорация» траст компаниясе» ААҖ һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе белән берлектә үткәрелде.

tatar-inform.

Фото: © «Татар-информ»

Урманайда да Гариф Галиев музее бар

Хөрмәтле минем яраткан газетам «Мәдәни җомга»!

Газетаның 18 август санында Әгъзам Фәйзрахмановның безнең авылдаш язучы Гариф Галиев турында «Җаваплы шәхес» дигән мәкаләсендә «Авыл китапханәсендә күргәзмә оештырылган», диелгән. Дөрес, анда даими эшләп килүче китап күргәзмәсе бар. Моннан тыш Урманай урта мәктәбендә дә авылдашыбызның бик бай музее бар. Зурлап аның 100 еллык юбилеен уздырганда безгә кунакка Кыям ага Миңлебаев язучының улы Яшәр әфәндене һәм оныгы Марсны алып килгән иде. Алар бик күп материаллар алып килде һәм шулар нигезендә мәктәптә музей оештырылды, аның алыштыргысыз җитәкчесе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ихсанова Эльвира Таһир кызы музейны тулыландыру өстендә һәрдаим эшли.

Язучының 100 еллык юбилеена да Яшәр әфәндене чакырган идек, яшем 80 нән өстә, ерак юлга йөри алмыйм, диде. Юбилейны аннан башка гына уздырдык. Быел Гариф аганың туына 120 елны да зурлап 15 сентябрь көнне билгеләп үтәргә җыенабыз, мәктәбебезгә дә 100 ел тулуны шушы көнне уздырырга ниятлибез. Мәктәбебез горурлык белән Гариф Галиев исемен йөртә. Гариф аганың туган нигезенә истәлек тактасы куелды.

Сиринә ГАЛИЕВА.

Тукай музеенда күргәзмә

Казандагы Габдулла Тукай исемендәге Әдәби музейда «Мирас» күргәзмәсе ачылды. Анда Казанның 1 нче һәм 7 нче балалар сәнгать мәктәпләре укучыларының эшләре тәкъдим ителә. Күргәзмә Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елына багышлана.

Тукай Әдәби музеенда еш кына танылган һәм билгеле рәссамнарның шәхси күргәзмәләре уза, шагыйрьнең тормышы һәм иҗат мотивларын ектыртькан тематик күргәзмәләр оештырыла. Казан сәнгать мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрнең эшләрен музейда күрсәтүне оештыру күркәм традициягә әверелгән.

«Мирас» күргәзмәсе – Тукай Әдәби музее белән 1 һәм 7 нче балалар сәнгать мәктәпләренең беренче уртак проекты. Бу сәнгать уку йортлары Татарстан Республикасы милли сәнгатен өйрәнүгә, уку процессында балаларны рухи-әхлакый үстерү һәм этномәдәни белем бирүгә, иҗади актив шәхесләр тәрбияләүгә зур игътибар бирә.

«Мирас» күргәзмәсе яшь рәссамнарның графика һәм рәсем эшләрен берләштерә, килгән кунакларны скульптура үрнәкләре белән дә таныштыра.

Күргәзмә 27 сентябрьгә кадәр эшләячәк. Аңа республикадагы рәсем сәнгатенең киләчәге белән кызыксынучылар чакырыла.

Э.СИРАҖИ.

Ук ату турниры узачак

Шушы елның 16 сентябрендә Алабуга шәһәрендә уктан ату буенча «Туган батыр» II Бөтенроссия турниры уза. Ярыш өчен федераль әһәмияттәге «Алабуга шәһәрчеге» мәдәни мирас объекты территориясе сайлап алынган. Турнирда катнашучылар, табигать белән хозурланып, палаткалар шәһәрчегендә яшәп, күчмә халыклар мәдәнияте белән дә таныша алачак. Анда һәркем дуслар һәм фикердәшләр таба, зирәк остазлардан үгет-нәсыйхәт туплый һәм турнирның 40 мең сумлык төп призы өчен көч сынаша алачак. Приз фонды 200 мең сумны тәшкил итә.

Турнирны Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Алабуга шәһәре һәм Алабуга районы мөхтәсибәте, Алабуга шәһәре һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы хакимияте, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы, Казан шәһәренең «Туган авылым» милли-туристик комплексы, Башкортстанның атка утырып ату һәм традицион җәядән атуны үстерү буенча «Мәргән уксы» автоном коммерцияле булмаган оешмасы; «МАКСАТ» ир-атлар спорт клубы, Татарстан Республикасының җәядән ату федерациясе берлектә оештыра.

Турнир халыкларның тарихи, этник, фольклор һәм мәдәни мирасын пропагандалау һәм өйрәнү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау; яшьләрне даими рәвештә спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү; уктан атуны популярлаштыру; Татарстанда туризмны үстерү; югары квалификацияле җәядән атучыларны ачыклау, әзерләү һәм камиллләштерү максатларында үткәрелә.

Турнирда Татарстаннан һәм Россия төбәкләреннән, шулай ук чит илләрдән 16 яшьтән өлкәнрәк ир-атлар һәм хатын-кызлар, 10-15 яшьлек балалар катнаша ала. Укчылар милли тарихи костюмнардан булырга, үзенең угын, җәясен һәм ук салу җайланмасын алып килергә тиеш. Турнир башланыр алдыннан, анда катнашучыларга кагыйдәләр белән таныштырыга һәм уктан ату вакытындагы куркынычсызлык техникасын мөстәкыйль рәвештә өйрәнергә кирәк булачак.

Ярыш җайдак, тездән ату, биатлон, һөҗүм, классик баганадан ату, тизлеккә ату, төрек путасы, еракка сөңге ату кебек 8 этапта уза. Икенче турнирның яңалыгы шунда: быел ярышта сөңге ату кебек яңа этап кертелә. Призлы урын алучыларның күрсәткечләре бертигез булганда, җиңүчене ачыклар өчен, тагын бер тапкыр уктан атып караячаклар. Бу «Җәя кереше» этабы дип атала.

Ярыш 16 сентябрьдә 9:00 сәгатьтә «Алабуга шәһәрчеге»ндә уза.

2022 елда I турнир да кызыклы узган иде. Анда Дагыстан, Башкортостан, Удмуртия Республикаларыннан, Әстерхан һәм Самара өлкәләреннән, Мәскәүдән, Санкт-Петербургтан, Татарстан районнары һәм шәһәрләреннән 65 укчы катнашты. Ярышны 7 мең кеше тамаша кылды.

Эльмира СИРАҖИ.

Актанышта яңа мәчет

Актаныш районы Табанлыкүл авылында яңа мәчет үз ишекләрен ачты. Рәсми тантанада Татарстанның төньяк-көнчыгыш төбәге казые, Актаныш районы имам-мөхтәсибе Руслан хәзрәт Мортазин, Казаннан «Габдерәхим Утыз Имәни исемендәге Ал Таң» мәчете имамы Ирек хәзрәт Җиһаншин, Актаныш районы башлыгы Ленар Зарипов, «Челтәр компаниясе» генераль директоры Илшат Фәрдиев, имамнар, эшмәкәрләр, авыл халкы катнашты. Яңа гыйбадәт йортына «Ак мәчет» дип исем бирелде. Аны төзетүдә тумышы белән шушы авылдан булган, хәзерге вакытта республикада хәйриячелек белән шөгыльләнүче киң күңелле Рузилә Шәймәрдәнова башыннан ахырына кадәр оештырып йөргән. Авылдашларның булышлыгы шушы изге гамәлне башкарып чыгарга көч-куәт биргән. Бүгенгә кадәр авылда мәчет булмаган, аңасы революциягә кадәр эшләгән мәчет урынында төзелде.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте вәкиле Ирек хәзрәт Җиһаншин Коръән һәм хәдисләрдән үгет-нәсыйхәтләр бирде, Аллаһны таныргa, дин юлында булырга, намаз укырга чакырды, Татарстан мөфтиятенең рәхмәт хатларын тапшырды.

Әлеге мәчеткә 2022 елның 24 нче июнендә нигез салынган. Быел ураза алдыннан – 21 нче мартта ай куелды. Мәчет 40 кешегә исәпләнгән, гомуми мәйданы 60 квадрат метрны тәшкил итә. Бер катлы итеп кирпечтән һәм яхшы сыйфатлы төзелеш материалларыннан төзелгән. Барлык уңайлыклар тудырылган тәһарәтханәсе бар. Газ, ут, су кертелгән. Мәчеткә имам итеп Рәсих хәзрәт Салихов билгеләнде.

Бүген Актаныш мөхтәсибәтендә 57 мәчет эшли.

Э.СИРАҖИ.

● Кеше миендә хәтер өчен урын бетә аламы? Әйе! Әмма әле бер генә инсанның да бу мизгелгә кадәр яшәгәне юк. Әгәр баш миен тәүлек буена эшли торган видеокамера итеп күз алдына китерсәң, анда 300 ел буе төшерерлек урын бар икән. Лимит хәтердә түгел, бәлки гомер озынлыгында! «Минем баш миемә артык күп эш йөкләнгән», дип әйтүчеләр бары тик аннан файдалана гына белми.

● 1638 елда Кытайдагы рус илчесенә бүләккә бернича капчык кипкән яфрак бүләк иткәннәр. Аның моңа бик хәтере калган, һәм аздан гына сугыш башланмаган. Ярый әле кемнендер әлеге яфракларны кайнар суга салып җибәтеп карарга башы җиткән, һәм менә шул вакыттан бирле инде без тәмле чәй эчеп хозурлана алабыз.

Хәтерлим әле, Роберт Миңнуллин минем юбилей уңаеннан язылган фикерләрен хат итеп юллаган иде. Нигәдер, мин аны үз вакытында тулысынча бастыра алмаганмын. Менә хәзер,егерме җиде елдан соң, бу кулъязманы архивымнан табып алдым да матбугатта чыгарырга булдым. Робертның рухы кире какмас дип уйлыйм.

Марсель ГАЛИЕВ.

Роберт МИҢНУЛЛИН

Кыланчык дустыбыз

Марсель Галиевне 27 ел беләм икән инде. Үзе бер гомер! Без яшьлектә бер үк тулай торакта яшәдек, университетның бер үк аудиторияләрендә укып йөргән булдык, бер үк мәҗлесләрдә, банкетларда тәгәрәп үстек. Еллар уза, гомер үзгәрә, чәчләргә чаллар куна. Марсель генә шул килеш. Талантын һәм холкын әйтүем.

Марсель – һичшиксез, талантлы әдип. Әдәбиятыбызның, бигрәк тә безнең буынның мактанычы – нәрсәгә генә, нинди жанрга гына тотынса да, әсәрләрен коеп кына куя. Шуңа күрә дә әдәбиятта, бигрәк тә әдәби мохиттә ул үзен шактый иркен тота. Хәтта, әйтер идем, кайчакларда бераз тәкәбберрәк кыланган чаклары да була. Андый чакларда ул безнең кебекләрне шагыйрьгә дә санамый башлый. Кәефе килмәгән вакытында классикларга да тел тидерергә күп сорамый. Аның өчен әдипләрнең күбесе урта куллар да халтурщиклар гына. Ә кем белә, бәлки, ул хаклыдыр да...

Әдәбиятка ул шагыйрь булып килде. Дөресрәге, «Беренче карлыгачлар»да бергәләшеп килеп кердек без шигърияткә. Әле булса бер шигъри исемлеккә кертәләр, бер җепкә тезеп йөртәләр безне. Әмма бер төрле ризык, бер төрле матурлык Марсельне тиз туйдыра. Шуңадырмы, студент елларында ук ул прозага тотынды. Бер-бер артлы повестьлар язып ташлады. «Шигъри проза остасы» дигән исеме телгә керде. Өлкәннәр дә, тәнкыйтьчеләр дә мактарга мәҗбүр булдылар. Ул – тел остасы. Ә.Еники белән Х.Сарьянның матур традицияләрен дәвам итүче, әдәби сүзгә гаять тә сак һәм игътибарлы әдип.

Яшьтәшләре җыр өлкәсендә бик активлашып киткәч, Марсель тагын түзмәде: «Әйбәт җыр менә шундыйрак була ул» – дип, берничә популяр җыр үрнәге иҗат итте. Әле хәзер дә шуларны тыңлап, зур канәгатьлек хисләре кичереп яши ул. Вакыт-вакыт яңа җырлары да яңгырап куя. Хикмәти Һода, һәр язганы диярлек уңышлы булып чыга.

Марсель университетның татар бүлегенә керсә дә, нишләптер журналистика бүлеген тәмамлады. Әмма журналист булып бөтенләй диярлек эшләмәде. «Никтер мәкаләләрең күренми, син бит журналист дипломы йөртәсең түгелме соң?» – дип кайчакларда төртмә сүзләр әйткәли идек, намусына тиде бугай. Олыгайган көннәрендә «Шәһри Казан» газетасында бераз эшләп алды. Газетада эшләгән чорда матур-матур очерклар, публицистик язмалар да язып күрсәтте. Без, аның белән бергә укыган дуслары, җиңел сулап куйдык. Юкка гына журналистика бүлегендә укымаган икән, диештек.

Әйткәнемчә, ул барысын да татып карарга ярата. Заманында балалар өчен хикәяләр җыентыгы чыгарган иде. Аннары балалар өчен шигырьләр китабы дөнья күрде. Минзәлә театры аның бер әсәрен сәхнәләштергән икән, дигән хәбәрләр дә йөрде. Әле күптән түгел китап кибетендә күрәм: Марсельнең өр-яңа юмористик хикәяләр җыентыгы сатылып ята. Өстәвенә, шул юмористик әсәрләрен сәхнәдән дә укыштыргалый. Тыңлаучыларның әйтүләренә караганда, тамашачылар көләләр дә икән әле, җитмәсә.

Соңгы вакытта Марсельнең тагын бер таланты ачылды. Ул – менә дигән мемуарист икән. Мемуарларны бездә аның кебек язучы булмагандыр әле, мөгаен. Х.Сарьян, Н.Дәүли, М.Мәһдиев турындагы язмаларын укыгач та: «Ниһаять, татарда да истәлекләр яза белүче табылды!» – дип, аһ иткәнемне әле дә хәтерлим. Тагын нәрсә генә кыландырыр икән дип көтеп йөрим менә...

Марсельнең әсәрләре җиңел укылса да, ул үзе шактый авыр һәм каршылыклы холыклы. Шуңа да карамастан, кешеләр белән тиз таныша, тиз аралаша һәм тиз генә бәхәсләшеп тә китә. Ул – «тусовка»лар, ягъни мәҗлесләр кешесе. Мин үскәндә, безнең өйгә каршы гына бер апа яши иде. Әгәр дә хат ташучыдан посылка-мазар алып кайтканны күреп калса, беттең. Берничә минуттан, берәр йомыш табып, шунда ук кереп житә. Посылка тартмасын ачып ятканны күреп: «И-и-и, белгән кебек килеп кергәнмен икән», – дип, күчтәнәчтән авыз итмичә чыгып китми торган иде. Марсель дә язучылар, журналистлар, артист халкы җыелган җирдән берчакта да калмас. Кем оештырган булуга карамастан, табынның түренә әләгер, һичшиксез, үзенә игътибар иттерер һәм, әлбәттә, мәҗлес дилбегәсен үз кулына алыр. Ахырдан мәҗлестә утыручылар: «Рәхмәт, Марсель, әйбәт сыйладың, мәҗлесне бик әйбәт оештыргансың», – дип таралышалар. Хәзер инде аның белән күптән бергә туры килгән юк. Элек нәкъ шулай була торган иде.

Марсель – үз имиджын үзе тудырган кеше. Ул – нечкә күңелле. Ихластан сөйләшә белә, эч серләрен дә бушаткан чакларын хәтерлим. Күңеле тулган чаклары да еш була. Шул ук вакытта ул – каты бәгырьле дә, үзеннән өлкәннәргә дә, дусларына да катырак сүз әйтүдән кыенсынмас, үпкәләтермен дип уйламас. Әмма бераздан берни булмагандай сөйләшә башлар, аннан күңеленә күрер, яңадан дустанә халәтенә кайтыр. Әйе, аны яратып, өнәп бетермәүчеләр дә бардыр. Шулай да күпме генә туры сүзле булмасын, Марсельнең дошманнары юк дип беләм. Ни өчен дисәң, ул берчакта да түрә булмады, булырга да теләмәде, беркайчан да, үзе әйткәнчә, «бәлеш»ләр бүлүдә катнашмады. Әмма үзенә дигән өлешен кулыннан ычкындырмады.

Күпме генә кырыс булса да, аның үзен яраттыра торган хикмәти бер сыйфаты бар. Тормышта ул яхшы мәгънәдә уйнап яши. Үзенең сентиментальлеген, оялчанлыгын, авыл тәрбиясен нигәдер кимчелек дип исәпли һәм аны яшерергә тырыша. Аның бераз гына кыланчыклыгы да шуңардан киләдер шикелле. Шунысы кызык, Марсельнең оялчанлыгын күпләр табигый кабул итә, чөнки ул кешеләргә ошый белә. Үзенең фикерләрен, карашларын кешегә сеңдерә ала. Бигрәк тә яшьрәк әдипләр арасында ул инде йөзә генә. Бездән соң килгән бер төркем шагыйрьләрнең шигъри тәрбиячесе М.Әгъләмов булса, әдәбиятка, әдәби мохиткә, язучыларга бәя бирү җәһәтеннән аларда, әлбәттә инде, М.Галиев тәрбиясе.

Мактанырга Марсельне генә куш! Аның сүзләренә ышансаң, Азнакай – иң матур төбәк; Чатыртау – Урал тауларыннан да биегрәк; авыллары янындагы исемсез инеш – Агыйдел белән Сөннән дә гүзәлрәк. Ә инде татарда Марсель Галиев кебек талантлы язучы, гомумән дә, юк. Һәм тиз арада гына булуы да көтелми...

Марсельнең кыланчыклыгы кайчакта туйдырып та куя. Әмма аңа шул кадәр өйрәнелгән, әгәр дә бераз гына югалып торса, без аны юксына башлыйбыз. Аның белән бәхәсләшәсе, әйткәләшеп аласы килә, тел кычыта башлый. Шунысы да бар: ул үзе дә үпкәли белми, эчендә үч саклап йөрми. Шуңадыр инде, әлеге сүзем дә аның үзенчәрәк килеп чыкты...

Менә шундый ул безнең талантлы язучыбыз, кабатланмас шәхесебез, кыланчык дустыбыз Марсель Галиев.

6 октябрь 1996 ел.

■ **Атнаның сәяси мизгелләре**

Серле сәфәрләр атналыгы

Узган атна ниндидер серле сәфәрләр һәм яшерен сөйләшүләргә бай булды. Ул Төркия президенты Р.Эрдоганның Сочида Россия лидеры В.Путин белән очрашып сөйләшүеннән башланды. Рәсми мәгълүматларга караганда, анда В.Путинның Төркиягә бер миллион тонна ашлыкны ташламалы бәягә сатып һәм анда эшкәртеп (онга әйләндереп), Африканың мохтаҗ илләренә җибәрү тәкъдиме хәл ителергә тиеш иде кебек. Milliyet газетасы шулай ук Төркия лидерының В.Путинга Украинадагы низагны җайга салуда арадашчы булу тәкъдиме белән мөрәҗәгать итәчәге турында да язып чыкты. Әмма мәгълүмат чараларында сөйләшүләрнең нәрсә хакында барганлыгы һәм сәфәрнең конкрет нәтиҗәләре турындагы хәбәрләр нигәдер бик аз булды. Ихтимал, анда ике яклы мөнәсәбәтләргә һәм актуаль халыкара проблемаларга кагылышлы темалар да игътибар үзәгендә булгандыр. Әмма алары да әлегә намәгълүм. Бары тик шул ук Milliyet газетасында гына очрашу нәтиҗәләренә карата Р.Эрдоганның, Украинада тынычлык урнаштыру перспективасы офык артында әлегә күренми, дигән фикере әйтелде. Анда шулай ук БМО Генераль Ассамблеясеннән соң (ә ул 19-26 сентябрьдә узачак), бу ике лидерның яңадан очрашып сөйләшү мөмкинлеге турында да әйтелә. Әлегә Украина буенча тыныч сөйләшүләр өчен җирлек булмавы турындагы сүзләр Кремльдән дә ишетелә.

Янә бер серле сәфәр АКШ дәүләт секретаре Э.Блинкенның 6 сентябрьдә кинәт кенә Киевкә кылган визиты белән бәйле. АКШ Дәүләт департаменты аның рәсми максатларын Украинада бүген бара торган контрһөҗүм белән бәйле һәм бу илне торгызуга кагылышлы проблемаларны ачыклау ниятендә, аның җитәкчеләре (президент, Премьер-министр һәм тышкы эшләр министры) белән очрашып сөйләшү буларак билгеләгән. Әле-ге сөйләшүләрдә Украинага алга таба да хәрби һәм финанс ярдәме күрсәтү, оборона өлкәсе сәнәгате белән бәйле хезмәттәшлек, Зеленскийның «тынычлык формуласы»н алга этәрү, ашлык экспортын киңәйтү кебек һ.б. мәсьәләләр дә күтәрелгән. Әмма бериш сәяси күзәтүчеләр әлеге сәфәрнең Украинада чәчәк ата торган коррупция һәм читләргә хезмәт итү белән бәйле булуы турында да әйтә. Кайбер мәгълүматларга караганда, август ахырында Украинаның коррупциягә каршы көрәш органнары башлыклары Вашингтонда булган һәм анда Киевтәге күп кенә күңелсез хәлләрне фаш иткән. Мәгълүм бизнесмен Коломойскийның кулга алынуы, саклану министры Резниковның отставкага җибәрелүе кебек фактларның да нәкъ Блинкен Киевкә килер алдыннан кылынуы да күп нәрсә турында сөйли. Ә Блинкен Киевкә, президент Байден кушуы буенча, күрәсең, әлеге чуалчык мәсьәләләрне урында хәл итү өчен дә килгән.

Инде сәяси атнаның кайбер башка вакыйгаларын да билгеләп үтик. Франция тышкы эшләр министры Катрин Колонна Европа имиләгенең яңа архитектурасын барлык илләр, шул исәптән Россия мәнфәгатьләрен дә исәпкә алып булдырырга чакырган. АКШ юстиция министрлыгы Россиянең халыкара санкцияләр аша «туңдырылган» активларын Украинага тапшыру тәкъдиме белән чыккан. Украина парламенты отставкага киткән саклану министры А.Резников урынына Дәүләт милке фонды башлыгы булып эшләгән Рөстәм Умеровны (ул кырымтатар халкы вәкиле) билгеләгән. Ашлык алыш-биреше яңарту һәм Россияне анда кайтару өчен, БМО Россельхозбанкны SWIFT системасына тоташтырырга тәкъдим иткән. АКШ һәм Әрмәнстан 11-20 сентябрь көннәрендә соңгысының «Зар» дигән өйрәнүләр үзәге базасында «EAGLE PARTNER» дип аталган хәрби өйрәнүләр үткәрә.

Фоат УРАЗАЙ.

Җәлилгә тиң каһарман

Рафис Корбанның әдәби иҗат казанышлары барыннан да бигрәк нәниләр шигърияте белән бәйле. Дөрес, әдәбият сөючеләргә ул үзенең лирик һәм публицистик шигырьләре, шигъри тәрҗемәләре, шулай ук балалар драматургы буларак, курчак театры репертуарын баету юнәлешендәге иҗат эшчәнлеге дә аша да яхшы таныш.

Проза жанрында Р.Корбан чынлап торып әле 4-5 ел гына шөгыльләнеп килә. Бу өлкәдә дә ул үзенең югары иҗат потенциалын күрсәтергә өлгерде. Биш ел эчендә үзенең укучысына биш роман, ике повесть бүләк итеп, ул безне шаккатырды. Әлбәттә, саны белән генә түгел, бу әсәрләрнең сыйфаты белән дә. Чөнки бу әсәрләрнең нигезендә кешелеккә иң кирәкле, иң кыйммәтле сыйфатлар – гаделлекне, дөреслекне казып чыгару ята. Менә шуның өчен дә бу әсәрләр алдында баш ияргә мөмкин. Алар сәнгатьчәнлек ягыннан да гаҗәеп камил эшләнгән. Шулар арасыннан соңгысы – «Алиш» әсәренә тукталыйк.

Абдулла Алиш, озак еллар буена ничектер шулай килеп чыкты, Муса Җәлилнең күләгәсендә калып килде, «Җәлил һ.б.» дип санап үтелгәндә генә телгә алынды. Асылда исә, А.Алишның татар халкы алдындагы каһарманлыгы да, аның язучы буларак дәрәҗәсе, гомумән, әсәрләренең сыйфаты, аларның әһәмияте ягыннан караганда да ким түгел. Менә шундый авыр эшкә алынган Рафис. Һәм гаҗәп дәрәҗәдә хикмәтле әсәр иҗат иткән.

Әлеге әсәр Рафисның иҗатында гына түгел, татар әдәбиятында да кискен борылыш ясарга сәләтле булып чыккан. Сюжеты, әлбәттә, катлаулы түгел. Алишлар язмышын без яхшы беләбез. Ләкин М.Җәлилдән соң Алишны язу – авторга өстәмә кыенлыклар да тудыра. Җәлилчеләр турында язылганнарны кабатламаска кирәк. Рафис үзе дә Җәлил һәм җәлилчеләр турында «Ватан» романын язды. Менә шунда язылганнарны кабатлау куркынычы бар иде. Рафис кабатламаган, киресенчә проблеманы тирәнәйткән һәм аны килечәккә алып барыр көч, импульс биргән. Әсәрдә татар халкындагы ике социаль катламның фаҗигасе ята. Бер якта – Бөек Ватан сугышында җитәкчеләребезнең икейөзле сәясәте аркасында беренче елда ук әллә ничә миллионлаган совет сугышчысының әсиргә төшүе, аларның салкында, ачлыкта үлемгә дучар булуы, икенче якта – безнең татар эмигрантлары, шул исәптән, әйтик Швейцариядәге «Мерседес-бенц» автомобильләрен җитештерү фирмасының генераль директоры Әхмәтвәли Мәңгәр, сәүдәгәрләр Искәндәр Яушев, Шәфи Алмас, Рәшит Рәхмәти Арат, Гаяз Исхакыйлар. Бүгенге көндә дә хөрмәт итәрлек зур шәхесләр. Шушы ике көч шушындый авыр шартларда килеп очраша. Араларында уртаклык

бар. Нинди уртаклык: гади кеше булып калу, икенчедән – милләт язмышы. Һәм монда бик зур проблема килеп чыга: патриотизм темасы. Патриотизмны кем ничек аңлый. Әйткәнебезчә, Гаяз Исхакый патриотизмны үзенчә аңлый. Милләт патриотизмы итеп. Җәлилләргә килсәк, гомумән, совет патриотизмы, ил патриотизмы. Бездә патриотизм темасы бүгенге көнгә кадәр хәл итеп бетерелгән тема түгел. Хәзер кем белән генә сөйләшсәк тә, һәркемнең үз патриотизмы. Кемдер эшкә барып, өенә кайтып, камфортно ял итүне күз алдына китерә. Кемдер милләте өчен көрәшүне күз уңында тота. Кемдер кулына корал алып иле өчен сугышка китүне патриотизм дип саный. Әлбәттә, Рафис та монда берьяклы гына итеп, менә шулай гына булырга тиеш дип әйтми, мөмкин дә түгел. Ул шушы ике төрле патриотизмны аңлауны алга куеп, берләштереп, нинди фаҗигале хәл килеп чыгу турында яза һәм гаҗәп дәрәҗәдә тирәнлеккә төшә. Әлбәттә, Алиш өчен дә, Җәлил өчен дә милләт өчен яну ят түгел. Исхакыйны без әле утыз биш еллар элек кенә фашист дип сүгә идек. Ә хәзер Фәннәр академиясендә хәзерләп, унбиш томлыгын бастырып чыгардык...

Гомумән, патриотизмны аңлау үзгәреп тора. Романда ике лагерь, ике катлам турында гына сүз бармый. Өченче катлам – укучылар. Ә укучылар гел үзгәреп тора. Шушы күзлектән караганда, бу әсәр Рафисның гаҗәп дәрәҗәдә зур ачышы. Ватан сугышы вакыйгаларын, патриотизм, милләт турында кайгыртуны ул бу роман белән дөньяга карашы үзгәрүчән укучы алдына китереп куя. Әйткәнемчә, сюжет катлаулы түгел. Монда яклар «Идел-Урал» легионын төзү буенча уртак бер фикергә киләләр, килешәләр. Җәлилләрнең язмышы ничек беткәне безгә яхшы билгеле. Алар компанионнарына биргән вәгъдәләрен бозып, аларга хыянәт иткән булып чыга. Нигә ирешәләр? Җәлил дә, Алиш та, башкалар да юк ителә. Ләкин әле моның белән генә бетми. Алар – шагыйрьләр. Әсирлектә дә шигырь язуны дәвам итәләр, дошманга каршы көрәшне шул рәвешле алып баралар. Мең бәла белән шигырьләрен төрмәдән чыгаруга ирешәләр. Нигъмәт Терегулов аларны Казанга алып кайтып, Алишның хатынына тапшыра. Алар Язучылар берлегенә барып ирешә. Гаҗәп дәрәҗәдә зур эш бит инде бу! Милләткә шагыйрьләрнең әсәрләрен алып кайтып тапшыру. Ни аяныч, Терегулов шул ук көннәрдә кулга алынып, атып үтерелә. Икенче кеше – Әмир Үтәшев, шулай ук алып кайтып, әле тапшырырга өлгермәгән була, ләкин гаепле дип табылып, 25 елга иреген мәхрүм ителә, Сөргенгә сөрелә. Ит яхшылык, көт явызлык килеп чыга. Ни өчен шулай? Патриотизмны төрлечә аңлау аркасында.

Бүгенге көннән торып караганда Алишның әсәрләре белән дә шул ук хәл. Мәктәпләрдә Алишның бөтен әсәрләре дә укыла, өйрәнелә, дип әйтсәк тә, бу әле канәгатьләнерлек дәрәҗәдә түгел. Чөнки илдә патриотизм төшенчәсенә мөнәсәбәт һаман бер төрле генә түгел. Илдә туган телләрне өйрәтү мәсьәләсе гаять аяныч хәлдә, хәтта елдан-ел проблема тирәнәя генә бара. Шуңа Казан мәктәпләрендә башка төрле патриотизм хөкем сөрә. Ә бит кешенең бәхете нәрсәдә? Шушы ике-өч төрле патриотизмны берләштерүдә. Күңелдә бербөтен итеп тоюда. Рафис шушы патриотизм темасы аша кешенең шәхес буларак таркалуын, гаҗәп дәрәҗәдә зур фаҗигагә килүен яза.

Бүген инде безгә Алишны да, Җәлил күләгәсеннән чыгарып, әдәбиятта аның мөстәкыйль үз урынын булдырырга вакыт. Чөнки Җәлил патриотизмы белән Алишныкы тышкы яктан бертөсле булса да, эчтәнрәк карасак, ике төрле патриотизм. Бүген без Алишка әдәбиятта, балаларны туган телдә укытып тәрбияләү эшендә Җәлил белән бертигез дәрәҗәдә урын бирергә тиеш. Ә без әле һаман 23 февраль, йә 9 май җиткәч кенә сугыш турында искә төшерәбез дә, Җәлил, Алиш һ.б. дип санап китәбез. Сугыш уңае белән генә түгел, Алиш тыныч вакытта да исебездә булырга тиеш. Татар балалары Алишны укып үсә... Балаларыбызны татар җанлы итеп үстерүдә Алиш әсәрләренең әһәмияте гаҗәеп дәрәҗәдә зур. Алишның дәрәҗәсен без әлегә кадәр күз алдына китерә алмыйбыз. Әлбәттә, аны Муса Җәлил белән каршы куярга ярамый. Ләкин алар бер-берсеннән ким дә түгел. Шуңа күрә хәзер әдәбиятта борылыш булырга тиеш. Без инде бертөрле патриотизм белән генә яшәргә тиеш түгел. Алиш патриотизмы белән дә яши башларга тиешбез. Алишны һәрбер мәктәпкә кертеп, аны өстәл китабы иттерергә тиешбез. Шкафның бер киштәсендә Коръән булса, икенчесендә Алиш китабы торырга тиеш. Менә шулай күрәм мин Алишның татар милләтендәге урынын. Рафис үзенең китабына шушы мәгънәне салган.

Равил РАХМАНИ,
әдәбият галиме, тәнкыйтьче.

КАЗАН КӨЗГӘ КЕРЕП БАРА

Казан көзгә кереп бара:
Җил уйный урамнарда,
Агачлар моңаешканнар,
Сагышка урангаhннар.

Казан көзгә кереп бара:
Сүрән кояш җылысы,
Җиләк-җимеш белән тулган
Көзнең сары тырысы.

Казан көзгә кереп бара:
Казансу дулкыннары
Талгын гына чайпалалар,
Чыгармыйча тыннарын.

Казан көзгә кереп бара:
Карыйм кирмән ягына. –
Йөзләрчә көз гамен җыйган
Моңлы бер көй агыла.

Казан көзгә кереп бара
Чал һава кочагында.
Гасырлар буйлап фасыллар
Йөгерә, оча гына.

Казан көзгә кереп бара
Әкрен генә, нык кына.
Көзге шау-шу – шау-шу түгел,
Күңелдә тынлык кына.

АКЛЫКНЫ САГЫНДЫМ

Кар ява, ап-ак кар –
Аклыкны сагындым.
Сак кына ак кына
Карларга кагылдым.

Кар ява, ап-ак кар,
Дөньяны матурлап.
Бу дөнья искиткеч
Тылсымлы, матур, ак.

Кар ява, ап-ак кар –
Агачлар аклыкта.
Бар җиһан күмелгән
Илаһи шатлыкка.

Кар ява, ап-ак кар,
Ак кына таң ата.
Күңелем аклыкны,
Сафлыкны ярата.

ТАТАРЫМНЫҢ ГАЗИЗ КЫЗЫ

Галимә, татар теле дәреслекләре авторы Рәдинә Ягъфәрованың якты истәлегенә

Түгел лә син милләтемнең
Артык кызы, ким кызы.
Син – халкымның йөрәгендә,
Рәдинә Хәким кызы.

Мәгърифәтче, остаз да син,
Акыл, гыйлем иясе.
Татарымның газиз кызы –
Барданың Рәдинәсе.

Нишләтәсең, читтә туа
Аңлы татар җанлылар.
Андыйларның исемнәре
Мәңге бакый яңгырар!

Синең хезмәтләрне күреп,
Очынып китә җаным.
Ерак сәфәргә кузгалдың,
Хуш бул, Рәдинә ханым!

Яңа буын сабыйлары
Телне, һичшиксез, отар!
Синең гыйлем орлыклары
Тиздән, бик тиздән шытар!

Татарга Катарга кадәр Җитмеш ел җитәр микән?..

Ленар ШӘЕХ

САМОЛЁТТА – 2

Яңгыр да юк монда, мәшәкать тә,
Бары кояш, кояш – тоташтан.
Иксез-чиксез аклык арасында
Адәмнәрнең уе буташкан.

Кемдер гәзит укый, кемдер йоклый,
Берәү исә фото төшерә.
Кайберәүләр очыш вакытында
Тулы гомер гүя кичерә.

Кемдер чәен эчә, кемдер ашый... –
Биеклектә кеше бу мәлдә.
Куркыныч та бардыр, ышаныч та... –
Ниләр уйлый икән бу бәндә?!

Якыннары җирдә дога укый,
Хәбәр көтә, ихлас борчыла.
Җир белән күк арасында шулай
Сөю дулкыннары кушыла...

Очкыч җиргә төшәр. Аклык калыр.
Иялэнгән тормыш башланыр.
Мәшәкатьләр, дөнья чолгап алыр,
Мең төрлегә хәят ясаныр!

Ярый ла ул күкнең аклыклары
Күңелләргә йогып калалса...
Үзем белән алып төшәр идем
Шул аклыкны... әгәр яраса.

КУАЛА-ЛУМПУР АЭРОПОРТЫ

Куала-Лумпур аэропорты.
Туктамый ява яңгыр.
Әйтә кебек: китәсең бит,
Шигырь дә язып калдыр.

Язам инде, ничек язмыйм! –
Илһам ташый җанымнан.
Күрешергә язсын әле
Киләчәктә тагын да.

Синдә дөньялар тоташа,
Төрле илләр, халыклар...
Синдә бар куе урманнар,
Елга, таулар, таллыклар.

Таллар янында бамбуклар,
Пальмалар, матур гөлләр.
Искитмәле гүзәллектә
Тын гына яшәр көннәр!

Беркем беркая ашыкмый,
Сулыу кабып чапмый.
«Мөселман!» дисәң, агайлар
«МашАллаh» дип кочаклый.

Азаннар яңгырап тора,
Мәчетләр – буй җитмәслек.
Бер күрсәң оҗмахтай илне,
Моннан мәңге китмәслек.

Һәрчак кояш көлеп тора,
Яңгырлар явыштыра...
Малайзия дуслаштыра,
Җаннарны кавыштыра.

Табигатьтәге җылылык
Күңел түрләрендә дә,
Бәрәкәт, муллык аларның
Суы, җирләрендә дә.

Бер генә аерма: монда
Кар һәм суык – ят әйбер.
Малайзиягә килгән җан
Якты моңга әйләнер.

Куала-Лумпур, Путраджая,
Атаклы Малай иле
Күңелемә кереп калды...
Әлегә сау бул инде!

ПАРИЖДА

Агачлар шау чәчәк аткан,
Иртән яңгыр, кич – кояш.
Парижның яктылыгында
Берни уйлый алмый баш.

Йөрәк буйлап хисләр ага,
Җылылыкка уралып.
Кичер мине, гүзәл шәһәр,
Килдем бераз соңарып.

Тойгыларым чиктән ашкан,
Сүзләрем – кайнар хисләр.
Урамнан барган кызларың
Серле, матур, нәфисләр.

Һәр почмагың – таң калырлык,
Вакыт тын калган кебек.
Күпме сокланып барсам да,
Бары тын алган кебек.

Чәчәк төргән агачларга
Карап көн-төн йөрмәле...
Биек-биек биналарың –
Бар да сәнгать үрнәге.

Сена ага. Ә Сенага
Карап тормыш агыла.
Дулкыннарда үткәнең дә,
Киләчәк тә чагыла.

Мең-миллионлаган кеше
Уза якты пар эздән.
Дулкын кебек дулкынланып,
Атлап киләм Париждан.

АЛЬБАТРОС

Истанбулда яңгыр ява,
Туктаусыз коя гына,
Чиксез болыт эләккәндәй
Җилле ат тоягына.

Яңгыр ява шыбыр-шыбыр.
Тәрәзәмнең каршында
Ана альбатрос утыра
Кечкенә оясында.

Истанбулда яңгыр ява,
Туктаусыз коя гына.
Тиздән кояш чыгар, чыгар
Диңгезнең бу ягына.

Кояш чыкса, кызудыр бит,
Төн җитсә, суык аңа.
Хәзер яңгырда күшегә –
Бер дә тынгы юк аңа.

Баласы чыкканын көтә.
Ничәү булыр, кем белгән?
Һәр ананың да йөрәге
Сөю белән чигелгән.

Ана – гомер бүләк итә.
Сабые буй җиткәнче
Кайгырта, карый, үстерә –
Өйдән чыгып киткәнче.

Балалар уенда – дөнья,
Аналар уе – бала.
Дөньясы фани булса да,
Ана шул килеш кала.

Альбатрос та балаларын
Тәрбияләр, үстерер.
Тегеләр диңгезгә очар,
Дулкыннарны үз күрер.

ТАТАРДАН КАТАРГА КАДӘР

Татардан Катарга кадәр
Әгәр сәфәргә чыксаң,
Җитмеш көн, җитмеш төн кирәк,
Җәяү юлга юлыксаң... –

Диләр, имеш. Дөрес микән?..
Ялган, әллә чын микән?..
Билдә билбау диеп торам,
Кылыч җуйган кын икән!

Татарда салкын, Катарда
Эссе – беркем күрмәгән.
Мөселманнарның йөрәге
Изге җир дип дөрләгән.

Ком эчендә бер-бер артлы
Оҗмахтай шәһәр туган.
Барысын да тигез итеп,
Фарсы култыгы юган.

Катарда иман ныклыгы...
Татарда зәгыйфь микән?
Аксакалларның телендә
Үкенү һәм «Их!..» микән?

Мөмкинлекне Аллаһ бирә,
Бер яшәрлек дөньясы.
Кемгәдер җәннәт оясы,
Кемгәдер – эт оясы.

Җавап белән куркыталмыйм...
Һәркем җавап тотасы.
Гөнаh арасында калган
Савапныңмы уртасы?..

Еллар барысын тигезли,
Чорлар – гел үзгәрештә.
Данлы һәм канлы дәверләр
Күтеп тора гарештә...

Татарга Катарга кадәр
Җитмеш ел җитәр микән?
Аңа кадәр Татар үзе
Сау калыр, бетәр микән?

ИСХАКЫЙ –

(Ахыры. Башы 35 нче санда).

Моның өчен, әлбәттә, милли идеологиянең, татар җәмгыятенең барлык катламын да берләштерү максатын күздә тоткан «бердәм агым» теориясенең авторы булган Гаяз Исхакыйның абруен җәмәгатьчелек алдында төшерү, түбәнсетү кирәк иде. Татарстан партия оешмасының ул вакыттагы җитәкчеләре директив органнар белән берлектә Гаяз Исхакыйга каршы көчле кампания башлап җибәрделәр. Алар бу өлкәдә Америка ачып тормадылар, бәлки инде егерменче елларда ук сыналган ысулга – Г.Ибраһимов кебек дәрәҗәле, абруйлы татар язылыларының куллары белән утлы күмер тоту методына мөрәҗәгать иттеләр. Нәтиҗәдә тарих фәннәре докторы У.Белялов белән фәлсәфә фәннәре докторы К.Фасеевның Татарстан җәмәгатьчелеген аякка бастырган, аны нәфрәтләндергән һәм әрнеткән «Гаяз Исхаки, он же «Шольц» дигән мәкаләсе «Советская Татария»дә басылып та чыкты. Әлеге гаугалы мәкаләгә кадәр дә Гаяз Исхакыйны пычраткан һәм түбәнсеткән чыгышлар булып алды. Әйтик, 1988 елда К.Фасеев «Не все то золото...» дигән мәкаләсен «Советская Татария» газетасында, ә Уфада яшәүче З.Нургалин «Ватанга хыянәт итүне аклап булмый (Г.Исхакый турында)» дигән язмасын «Кызыл таң» газетасында бас-тырып чыгардылар. Нәтиҗәдә киң җәмәгатьчелек арасында фикер төрлелеге туды, Гаяз Исхакыйның әдип һәм көрәшче буларак абруена, намусына зур күләгә төште.

Тарих фәннәре докторы У.Белялов һәм фәлсәфә фәннәре докторы К.Фасеев имзасы белән «Советская Татария» газетасының 1989 ел, 19 февраль санында дөнья күргән «Гаяз Исхаки, он же «Шольц» дигән мәкаләдә Г.Исхакый исеменә сылтап гаять зур концептуаль бурыч – көч туплап килүче азатлык хәрәкәтен милли идеологиядән мәхрүм итеп, аны коралсызландыру һәм нәтиҗәдә хакимият тәгълиматына ныгыту максаты куела. Милли идеологиянең гәүдәләнеше булган Гаяз Исхакый шәхесен фашистлар Германиясе җитәкчелеге белән бәйләп, халыкта аңа карата нәфрәт хисен уятып, шул җөмләдән милли азатлык хәрәкәте юлбашчыларын да изоляциядә калдыру кебек сәяси-стратегик планны үз эченә алган әлеге мәкалә бу идеология көрәшендә сәяси дивидентлар китерергә тиеш була. Махсус органнар ярдәмендә табылган кайбер фактлар нигезендә мәкалә авторлары Гаяз Исхакыйның 1917 елга кадәрге һәм аннан соңгы чордагы тормыш юлын күздән кичереп чыгалар, аның әдәби иҗатына, иҗтимагый-сәяси һәм милли эшчәнлегенә коммунистик идеология күзлегеннән чыгып бәя бирәләр. Ләкин провокациянең иң мөһим детале итеп «Шольц» псевдонимы кулланыла. Мәкалә авторларының һәм алар артында торучы көчләрнең логикасы мондый: әгәр Исхакыйга «Шольц» дигән яшерен исем бирелгән икән, димәк, ул тикмәгә түгел. Икенче исемнең разведчикларга һәм шпионнарга бирелүен истә тотып, аны рәхәтләнеп «немец шпионы» дип игълан итәргә була! (Исем немецныкы бит!) Исхакыйны һәм милли идеологияне әнә шулай йөзләрчә миллион кешенең гомерен өзгән нацистлар тәгълиматы белән бәйләп, җәмәгатьчелектә милләтчеләргә карата негатив фикер тудырырга һәм бер селтәнү белән хакимият өчен куркыныч тудырган көчләрне дә авызлыкларга, нейтральләштерергә мөмкин!

Гади генә газета мәкаләсе кебек тоелган бу язманың төбендә әнә шундый хәтәр һәм куркыныч сәяси гамәл, СССРда башланып киткән гомумдемократик һәм милли процессларның табигый үсешен туктату яки, һич югы, аларны акрынайту максаты ята. Моны тормышка ашыру өчен, «Шпион Исхакый», «антикоммунистик әсәр булган «Зөләйха» пьесасының милләтче авторы» кебек фактлар һәм аргументлар белән артык көчле ныгытылмаган төшенчәләр файдаланыла. «Республикада рухи мирас комиссиясе»нең киңәйтелгән утырышта катнашучы галимнәр һәм язылылар логик дәлилләр ярдәмендә У.Белялов белән К.Фасеев мәкаләсендәге шушы яла ягулы тезисларны кире кактылар. Бу уңайдан чыгыш ясаган Ф.Мусин, И.Нуруллин, Б.Мәхмүтов, М.Әхмәтҗанов, Ә.Еники, Р.Мостафин, А.Әхмәдуллин, Н.Юзиев, М.Мәһдиев, Ә.Кәримуллин, Б.Гыйззәт, Ә.Рәшитов, К.Габдерәзов, Р.Мөхәммәтдинов, Г.Фәйзерахманов, Ф.Сафин, Д.Исхаков һ.б.лар мәкалә авторларын нык тәнкыйтьләүдән һәм җыелышның карары белән матбугат, радио, телевидение аша киң җәмәгатьчелекне дә таныштырырга тәкъдим иттеләр. Соңыннан сүз алган Умәр Белялов үзенең хатасын тануын белдереп болай диде: «Мин мондый очрашуны озак һәм куркып көттем. Бу көнгә кадәр яшәвемә шатмын. Мин үзем Сталин репрессиясе корбаннарын күтәргән кеше. Мин Исхакыйның Октябрьгә кадәрге эшчәнлеген дә күтәрергә тырышачакмын. Мин кайчандыр шагыйрь Хәсән Туфан турында чыгыш ясаган идем. Ул миңа рәхмәт әйтте, күңеле булды. Бүгенге сөйләшү мине җитди уйлануларга этәрә. Минем алда Исхакыйның әдәби мирасын бастырып чыгарыргамы-юкмы дигән сорау тормый. Мин аның әсәрләрен халыкка җиткерү ягында. Бүгенге тәнкыйть сүзләрен кабул итәм. «Советская Татария»дәге мәкаләбез берьяклы булып чыккан. Әгәр көчем җитсә, Исхакыйның Октябрьгә кадәрге чоры турында объектив мәкалә язып бастырырга тырышачакмын».

Әлеге җыелыштан соң Г.Исхакый мирасына каршы оештырылган «һөҗүмнәр» кимеде. Җәмәгатьчелекнең бердәм рәвештә белдерелгән кискен фикере белән КПСС өлкә комитеты функционерлары да санашырга мәҗбүр булдылар. Һәрхәлдә, 1989 елның 1 мартыннан соң Г.Исхакый иҗатын кайтару эше беразжиңеләя төште.

Бу очракта дөреслек хакына танырга кирәк: Гаяз Исхакый, киң колачлы сәяси эшлекле буларак, татар диаспорасы белән актив эшләү өчен бик күп чит илләрдә булган. Германия, Польша, Төркия, Финляндия, Кытай, Япония кебек дәүләтләрдә якташларыбыз оештырган милли-мәдәни җәмгыятьләр белән Г.Исхакый тыгыз бәйләнештә торган, аларга методик һәм башка характердагы ярдәмне күрсәткән. Ләкин ул бер генә чит ил разведкасы белән дә бәйләнешкә кермәгән һәм әлеге илләрнең махсус хезмәтләре дә, Г.Исхакыйның холык-табигатен һәм сәяси карашларын яхшы белгәнгә күрә, уемча, аның белән нинди дә булса мөнәсәбәткә кермәгәннәрдер. Бу фикернең дөреслеген Япониянең Хосей университеты профессоры Камозава Ивао да үзенең «Татарлар Японидә» дигән биш табаклык фәнни хезмәтендә раслап тора. Ул Япония Эчке эшләр министрлыгы архивы документларына таянып язылган бу хезмәтендә Гаяз Исхакый турында да кызыклы мәгълүмат китерә.

«Хьего префектурасы тышкы эшләр полициясе бүлегенең 2207 нче номерлы яшерен хәбәре
1934 ел, 19 июль
Сиране Такусуе Хьего префектурасы начальнигы
Гото Фумисо әфәндегә
Эчке эшләр министрына
Элеккеге кайбер русларның шәхесләре карау өчен төрек илчелегенең тапшыруына карата.

Түбәндә телгә алына торган элеккеге русларның һәрберсе, хәбәр иткәнчә, Төрек илчелегеннән төрек гражданлыгы сораган. Илчелек безнең префектура хезмәтенең тышкы эшләр полициясе бүлегенә мөрәҗәгать иткәнлектән, копияләре алынган түбәндәге өч хаттан күренгәнчә, бүлек бу өч кеше турында мәгълүмат туплады. Советлар белән тыгыз элемтәдә торуда гаепләнмәс өчен аларның төрек гражданлыгы алырга теләүләре һәм аларның гражданлыгы кешеләрнең хокуксызлыкларыннан котылу өчен шундый гамәл кылулары исбатланды. Аннан соң татар кешесе Гаяз Исхакый килде, һәм әлеге өч кеше Г.Исхакый җитәкләгән милли хәрәкәт белән мавыгып киттеләр. Алар нинди дә булса шик тудырмау сәбәпле, безнең хезмәт, алда күрсәтелгәнчә, илчелеккә җавап бирергә тырышты. 1915 елның 4 декабрендә Тышкы эшләр министрлыгы тарафыннан расланган «Илчелек персоналы белән аралашу турында»гы 4 нче номерлы инструкция булганлыктан, без Тышкы эшләр министрлыгы вәкиллеге аша җавап бирергә тиеш дип аңладык. Без Тышкы эшләр министрлыгы сезнең күрсәтмә буенча җавап бирер дип ышанабыз.

Һәм шул хакта хәбәр итәм».

Әлеге документтан күренгәнчә, Гаяз Исхакый милли хәрәкәтне оештыру, гамәлдәгеләренә ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнгән һәм үзе булган илнең эчке эшенә дә тыгылмаган, аның махсус хезмәте белән аралашу юллары да эзләмәгән. Г.Исхакый артыннан күзәтү алып барган яшерен полиция агенты бу фактны әнә шулай үзе үк раслап тора.

● Г.Исхакый Архангел өлкәсендә сөргендә. 1908 ел.

Гаяз Исхакыйның өченче рейх белән дә бернинди бәйләнешкә кермәвен раслаучы документлар һәм тере шаһитлар шактый. Шул арның берсе – журналист, күренекле җәмәгать эшлеклесе, «Идел-Урал дәгъвасы һәм Совет империализмы» (Истанбул, 1963), «Идел-Уралда хөррият мөҗадәләсе» (Истанбул, 1985) исемле китаплар һәм «Исемдә калганнар» (Казан, 1994) дигән мемуар авторы, штаб-квартирасы ГФРның Мюнхен шәһәрендә булган Бөтендөнья татар лигасы президенты Гали Акыш. Ул – 1938 елдан алып 1954 елга кадәр Гаяз Исхакый белән бергә эшләгән, аның кушуы буенча милли азатлык хәрәкәтен дәвам иттерү өчен актив көрәшкән шәхесләрнең берсе. Хәзер сүзне аңа бирик:

«Икенче бөтендөнья сугышының беренче елларында нацистлар аңа үзләре эш алып барырга тәкъдим итсәләр дә, Г.Исхакый бу тәкъдимнәрен катгый рәвештә кире какты. Моның белән бәйле бер вакыйганы искә төшереп үтәргә телим. 1942 елның эссе бер июль көнендә Г.Исхакый мине Истанбулдагы өенә чакырган иде. Киттем. Анда Әнкарадагы Германия илчелегеннән ике кеше бар иде. Гаяз Исхакый мине шаһитлык өчен чакырган булса кирәк. Алманлылар сүз башлады. Алар, Германия гаскәре белән берлектә хәрәкәт итәчәк Идел-Урал легионы төзеләчәген хәбәр итеп, Исхакыйны, Бәйсезлек комитеты рәисе буларак, легион төзүдә ярдәм итәргә чакырдылар. Гаяз Исхакый, бу тәкъдимгә каршы килеп: «1) Идел-Урал дәүләте өчен хокукый гарантия; 2) корылачак легион өчен команда составы; 3) Идел-Урал Бәйсезлек комитетына мөстәкыйль милли хөкем органын төзү мөмкин булып тора», – дип, үз тәкъдимнәрен алга сөрде. Алманнар киң хокук таләп иткән бу тәкъдимнәр белән килешә алмый иде, һәм шул сәбәпле ике арада бернинди дә аңлашу була алмады. Һәм, гомумән, Гаяз Исхакый алманнарның җиңелүгә дучар булачакларын әле 1939 елда ук әйткән иде.

1942 елда Германиядә корылган Идел-Урал легионында вазыйфа алган кайберәүләр әйтүенчә, имеш, Г.Исхакый 1943 елда алманнар белән бергә хезмәттәшлек итәргә теләгән, әмма алманнар бу тәкъдимне кире каккан. Бу – бертөрле дә мантыйкый нигезе булмаган бер сүз. Әле 1942 елда, алманнар бөтен фронтларда җиңү арты җиңү яулаган бер вакытта, алар белән эш алып барудан ерак торган Гаяз Исхакый 1943 елда, алманнар Сталинградта җиңелүгә, Көньяк фронтта зур югалтуларга дучар булганнан соң хезмәттәшлек итү уенда ничек булсын икән?»

ДАВЫЛ ХӘБӘРЧЕСЕ

● Г.Исхакый гаиләсе белән (кызы Сәгадәт һәм кияве), Берлин, 1933 ел.

Татар халкы Милли мәҗлесенең шәрәфле әгъзасы Гали ага Акыш «Исемдә калганнар» дип аталган мемуарында да Гаяз Исхакыйның намуслы, гадел, алдан күрүчән зирәк сәясәтче, перспективасыз идеяләргә һәм буш вәгъдәләргә алданмый торган кеше булуына нык басым ясый.

Татар халкының рухи яңарышы өчен игелекле гамәлләр башкарган, берничә фәнни һәм шигъри китап авторы Минһаҗ Исмәгыйли дә «Татарга мин нәрсә теләр идем?» дип исемләнгән әңгәмә-истәлегендә, Гаяз Исхакыйның югары әхлаклы һәм ифрат дәрәҗәдә намуслы олы кеше булуын күрсәтеп, болай ди:

«Менә шундый иде. Кайбер даһилар йөз елга бер килсәләр, Гаяз ага мең елга бер килә торган кеше иде. Әгәр дә Гаяз ага шикелле биш-ун даһиебыз булса, без күптән азат милләт булыр идек инде».

Гаяз Исхакыйның Германиядәге Гитлер хакимияте белән хезмәттәшлек итмәвен Германиянең Потсдам шәһәрендәге Үзәк Дәүләт архивы материаллары да ачык раслап тора. Элеккеге ГДРда нәшер ителгән «Дөнья һәм социализм проблемалары» дип аталган журналның баш мөхәррире, тәрҗемәче һәм галим Леон Небенцаль ГФРдан алынган кайбер документларның күчермәсен Казанга җибәрә. Анда сүз Өченче рейх дип йөртелгән Германия империясе шәһәре Грайфсвальдта 1944 елның 4-5 мартында булып узган Идел-Урал халыклары (татарлар, башкортлар, чуашлар, мордвалар, удмуртлар һәм марилар) корылтае хакында бара. Аның эшендә шулай ук Германия империясенең сәяси, хуҗалык, административ органнары вәкилләре дә катнаша. Шул ук Грайфсвальд шәһәрендә 1944 елның 3-5 мартында ике йөзгә якын делегатны җыйган Идел-Урал төрки-татарларының утырышы да була. Оештыру, хәрби, пропаганда һәм финанс мәсьәләләрен караган бу утырышта «Татар арадашчылыгы» комитеты рәисе Шәфи Алмас (Гадбрахман Габидулла улы Шәфиев), комитет әгъзалары профессор Әхмәт Тимер, мулла Гани Усманов, фабрика хуҗасы Абдулла Яушев. «Немец-татар мәгълүмат бюллетене» баш мөхәррире Гариф Солтан, штаб-квартирасы Берлинда булган Төркестан комитеты президенты Вәли Каюм-хан, адвокат Генрих Унгляубе һ.б.лар катнаша. Әмма Балтыйк буе немецы Альфред фон Розенберг җитәкләгән оккупацияләнгән Көнчыгыш җирләр министрлыгының бер генә документында да, шул җөмләдән Леон Небенцаль тапкан «Идел-Урал халыклары корылтае» материалларында да Гаяз Исхакый исеме телгә алынмый. Әгәр ул нацистларның бу хәрәкәтенә теләктәшлек белдергән яки аны хуплаган булса, Геббельс пропагандасы Гаяз Исхакыйның данын әллә кайларга таратыр иде. Документ әзерләүдә һәм аны саклауда пөхтәлек белән аерылып торган немец-фашистлар, шул рәвешчә, үзләре үк У.Белялов белән К.Фасеевның «Исхакый – герман разведкасы агенты «Шольц» дигән версиясен кире кагалар. Димәк, бу версия элеккеге тоталитар системаның махсус хезмәте лабораториясендә укмаштырылган дезинформация булып чыга. Һәрхәлдә кулда булган материаллар һәм күпсанлы шаһитларның күрсәтмәләре шулай дип уйларга ныклы нигез калдыра.

У.Белялов белән К.Фасеевның һәм алар артында торган сәяси көчләрнең бу версиясе әнә шулай логик дәлилләр, җитди чыганаклар һәм ышанычлы документлар белән киң җәмәгатьчелек тарафыннан кире кагылгач, Гаяз Исхакый мирасына бирелгән элеккеге негатив бәяләр дә уңай якка үзгәрә башлады. Бу нисбәттән академик М.Хәсәнов та вакытлы матбугатта «Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре» дигән җитди теоретик хезмәт белән чыгыш ясады һәм күп гасырлык тарихи-мәдәни мирасны өйрәнүнең үзенчәлекле методикасын тәкъдим итте. Әлеге хезмәт яңалыгы, проблеманы тирәнтен аңлавы һәм әдәбият фәне алдында торган бурычларны төгәл күрсәтүе белән үзгәртеп кору чорына авазаш булды. Г.Исхакый мирасына булган мөнәсәбәтне үзгәртүдә дә уңай роль уйнады.

Шагыйрь Муса Җәлил иҗатын өйрәнүгә күп көч куйган филология фәннәре кандидаты Р.Мостафин да Г.Исхакый мирасын кайтару һәм пропагандалау эшенә мәгълүм өлеш кертте. Аның 1987 елның 26 июлендә басылып чыккан «Подъем затонувших сокровищ» һәм 1989 елның 25 июнендә дөнья күргән «Пояснения к пояснениям» дигән җитди мәкаләләре Гаяз Исхакыйның намуслы исемен кире кайтаруда һәм аның әсәрләрен пропагандалауда файдалы булдылар.

Гаяз Исхакыйның 1918 елга кадәрге шанлы исемен кайтару һәм аның күпкырлы сәяси-әдәби мирасын гыйльми әйләнешкә кертү өчен актив көрәшкән мәрхүм профессор И.Нуруллин хезмәтләре дә (бу темага ул 26 мәкалә язды) хөрмәткә һәм олы ихтирамга лаек. Аның «Два письма М.Горького», «Возвращение Гаяза Исхаки», «Горькийның ике хаты», «Реплика в порядке уточнения», «Гаяз Исхакый», «Макталган һәм тапталган әдип», «Не спорить, а изучать», «Во имя научной объективности», «Кайту», «Кадерле рәсем», «Гаяз Исхаки о себе», «Әдип эзләреннән – Төркиядә», «Үзенә лаеклы булып кайтсын иде», «Гаяз Исхакый (Әдипнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлегенә бер күзәтү)», «Тукай һәм Гаяз Исхакый», «Беренче һәм соңгысы», «Начармы, яхшымы – үзебезнеке», «Гаяз Исхакыйга йогынты» дигән хезмәтләре бүгенге көндә дә Гаяз Исхакый иҗатын өйрәнү һәм бәяләү эшендә кыйммәтле чыганаклар булып хезмәт итәләр.

● Татарстан мөфтияте вәкилләре Г.Исхакыйның Истанбулдагы кабере янында. 2008 ел.

Җәмәгатьчелек фикеренең шулай Гаяз Исхакый ягына авыша баруын күреп, рәсми хакимият тә, кайбер икеләнүче зыялылар да, карашларына төзәтмә кертеп, яңа ситуациягә җайлашу ягын карадылар. Нәтиҗәдә 1991 елда, зур кыенлык белән булса да, Г.Исхакыйның «Зиндан» дигән сайланма проза һәм сәхнә әсәрләренең 37 табаклык калын тупланмасы дөнья күрде. Китапка кереш мәкаләне профессор И.Нуруллин, йомгаклау мәкаләсен театр белгече Һ.Мәхмүтов язды. Китап басылып чыгу белән үк таралып бетте.

Милли гуманитар фәннәрнең башка тармакларында эшләүче галимнәр дә Гаяз Исхакый иҗаты ягына якты йөз белән борылдылар. Аерым алганда, 1917-1918 елларда Идел-Урал төбәгендә барган милли азатлык хәрәкәтен гыйльми яктан өйрәнгән академик Индус Таһиров, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре Садри Максуди, Муса Бигиев, Галимҗан Баруди, большевик Мирсәет Солтангалиевләр турында хезмәтләр бастыргач, Гаяз Исхакый шәхесенә дә игътибар итәргә мәҗбүр булды. «Бердәм агым» теориясен нигезләгән Гаяз Исхакый турындагы материалларны өйрәнеп, И.Таһиров «Гаяз Исхакый һәм татар тарихы» дигән мәкалә бастырды. И.Таһировның әлеге хезмәте Г.Исхакыйның тарихи мирасын өйрәнергә алынучы яшь галимнәр өчен җитди методик һәм үзенчәлекле программа вазифасын үтәрлек югарылыкта язылган.

Гаяз Исхакый мирасын дөрес аңлауның, аның аерым бер әсәрен җентекләп анализлауның матур үрнәген биргән академик М.Госмановның «Гаяз Исхакый: «Ике йөз елдан соң инкыйраз» һәм патша цензурасы (Иҗатының яңа сәхифәләре ачылу)» дигән шактый күләмле хезмәте XX гасыр башы татар әдәбиятының иҗтимагый-мәдәни эчтәлегенә төп юнәлеш сызган үзенчәлекле әсәрнең лейтмотивын өр-яңача аңлавы белән әдәбият белемендә зур ачыш булды.

М.Госманов Санкт-Петербург архивларының берсендә Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренең патша цензоры В.Л.Смирнов тарафыннан «кыркылган» өлешләрен табып ала һәм шуларны үзенең комментарийлары, искәрмәләре белән бастыра. Ул биредә текстолог буларак та, галим сыйфатында да чыгыш ясап, патша цензоры гарипләгән әсәрне сәламәтләндерү, әсәр текстындагы өзелгән фикерләрне һәм шул рәвешчә бозылган мәгънәләрне табигый халәтенә китерү буенча зур көч куя. Әйтергә кирәк, галимнең мондый титаник хезмәтен кеше организмына яңа әгъза кую өчен ясалган катлаулы операциягә тиңләп булыр иде. Бәхеткә каршы, М.Госманов бу авыр бурычны уңышлы башкарып чыккан һәм нәтиҗәдә Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренең йөзе тагын да чибәрләнеп, төп аһәңе сафланып, сюжет-композициясе төзекләнеп киткән. «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ның М.Госманов тарафыннан тулыландырылган, мәгънә-эчтәлеге киңәйтелгән варианты халыкара «Мирас» журналының 1997 елгы 2 нче һәм 3 нче саннарында дөнья күрде.

Миңнәхмәт СӘХАПОВ.
«Бердәм агым» китабыннан.
ТКН, 2006.

Мәдәни җомга
15 сентябрь
№36, 2023

ДӨЯ КҮЗЕ

Чыңгыз АЙТМАТОВ

(Дәвамы. Башы 35 нче санда).

Менә хәзер дә мин сулы мичкә белән маңың янына якынлашып килəм, ә ул һаман ярсуыннан тыела алмый, сөргән җиргә бата-бата, миңа каршы йөгерә.

– Нигә өстерәләсең гарип бет шикелле! Күпме көтәргә мөмкин сине? Буып үтерәм бит, көчек, дөньяда бер маңка Академик азрак булыр.

Мин, бер сүз эндәшмичә, трактор янына барам. Нәрсә дип акланыйм инде? Трактор минем аркада туктаган ич, анысы факт. Ярый әле прицепщик Хәлифә мине яклап арага керә:

– Тукта инде, Әбәкер, тынычлан! – ди. – Акырып-җикереп кенә файда юк. Күр әнә, болай да төсе калмаган мескеннең, суырылып беткән. – Шулай дип, Хәлифә, минем калтыранган кулларымнан чиләкне алып, радиаторга су сала. – Болай да бик тырыша инде ул. Күр әнә, бөтен өсте манма тир – сыгып алырлык булган.

– Анда минем ни эшем бар! Өйләрендә китабын укып кына ятсын иде, – ди Әбәкер, чәпчеп.

– Йә, тукта инде, – ди Хәлифә, аны тынычландырмакчы булып. – Үзеңдә усаллык та бар соң! Алай яхшы түгел, Әбәкер.

– Моның ишеләргә һәммәсен дә гафу итеп торсаң, дөньяда яшәрлегең калмас. Планны бит синнән түгел, миннән сорыйлар. Шушы укымышлы сарык мине пычаксыз суйганын беләмени алар!

Каныкты бит минем шул укымышлы булуыма. Нигә укып йөргәнмендер, тарихчы Аллаяров каян килеп чыккандыр минем башка бәлагә?

Мин моннан тизрәк китеп барырга тырышам. Мине басуның теге башында да көтеп торалар бит әле. Анда Садабәк дигән тракторчы, өлкән яшьтәге, бик җитди кеше, ачуланса да, кычкырынмый-җикеренми.

Аргта гөрелдәп мотор кабынды. Әбәкернең тракторы урынынннан кузгалып китте. Мин дә җиңел сулап куйдым, тирләгән, юеш фуфайка эчендә тәнем чирап китте. Нигә шундый әшәке, явыз булып туган бу Әбәкер? Әллә ни карт та түгел бит әле, яше утыздан гына узгандыр. Дөрес анысы, бераз авыр чырайлырак, яңак сөякләре калкып тора, куллары келәшчә шикелле эләктереп кенә ала, шулай да килбәтле кеше үзе. Ә менә күзләре әшәке, яман итеп карый. Берни булса, күзләрен шундук кан баса, андый чакта инде сак бул – аны-моны уйлап тормый ул.

Әле күптән түгел бездә бер хәл булды. Киченнән яңгыр ява башлап, төне буе сибәләде, әллә нинди күңелсезлек, моңсулык таратып шыбыр-шыбыр яуды да яуды, киезләрне күбендереп, тирмә өстеннән акты. Яңгыр икенче көнне иртән дә басылмады. Без тирмәдә эшсез интегеп ятабыз. Агроном Сорокин каядыр киткән – яңгырда да эше муеннан аның. Ул бит терлекчелек өчен дә җаваплы, шуңа күрә бер минут та ял юк аңа, көннәр буе ат өстеннән төшми.

Яңгыр бераз басыла төшкәч, Садабәкнең энесе – прицепщик Әсәркәп тә, минем атны иярләп, каядыр чабаннар янына китеп барды. Әлдәй белән Хәлифә, чиләк алып, чишмәгә суга киттеләр. Тирмәдә без өчәү генә – Әбәкер, Садабәк һәм мин – калдык.

Һәркайсыбыз, сүзсез һәм кәефсез бер хәлдә, үз эше белән мәшгуль. Әбәкер, аякларын сузып, ята төшебрәк утырган да тәмәке тарта. Садабәк, астына ияр киезе салып, учак янына утырган, кулында без белән сумалалы җеп – тишек итеген ямый. Мин почмакка сыенып кына китап укыйм.

Тирмә эче юеш, күңелсез. Яңгыр суы сеңгән киезләрдән сарык исе аңкый. Өстән чәй төсле сары эре тамчылар тама. Тышта исә яңгыр әле һаман шыбырдый, җыелган сулар өстенә чылтырдап ява.

Әбәкер авызын ачып иснәде, буыннарын шытыр-шытыр китереп киерелде, аннары күзләрен йомды да карамый-нитми генә тәмәке төпчеген ыргытып җибәрде. Төпчек киез читенә барып төште, һәм шундук киез йоны көеп төтә дә башлады. Садабәк төпчекне алып көлгә ташлады.

– Абайлабрак кылан. Торырга иренәсеңмени? – диде ул, җебен суыра-суыра.

Әбәкер бер дә исе китмәгән кыяфәт белән баш калкытты да:

– Ә нәрсә булган? – диде.

– Киез яна башлады.

– Харап та зур байлык икән! – дип, Әбәкер авызын ерып көлеп куйды. – Тишек итегеңне ямыйсыңмы! Яма, яма, сиңа шуннан артыгы кирәкми дә.

– Эш байлыкта түгел, син бит монда ялгыз башың яшәмисең, үз өеңдә түгел.

– Үз өем түгел икәнен беләм! Үз өемдә булсам, мин синең белән сөйләшеп тә тормас идем. Аңладыңмы, күн ыштанлы гыйбад? Шушы каторга җирендә интегеп ятсын дип, Ходай каргагандыр мине. Син һәм синең хатының ише җүләрләргә генә ярый торган урын бу Анархай!

Садабәк каты итеп җебен тартып җибәргән иде – кулындагы безе, ычкынып китеп, баш артына очты. Усал ачу белән Әбәкергә озак кына карап торды да, бер кулына күн итеген, икенчесенә скрипка кылы шикелле тартылган җебен тоткан килеш, дәһшәтле кыяфәттә алга таба талпынып куйды:

– Яхшы, мин җүләр булыйм, минем белән бергә килеп, сезнең барыгызны да ашатучы хатыным да җүләр булсын! – диде ул, мышнап сулый-сулый. – Анархайга килгәннәрнең калган барысы да каторжаннармыни, синеңчә? Син китердеңмени монда аларны? Шулаймы, әйт, эт җан! – дип кычкырып җибәрде Садабәк һәм, уң кулы белән дагалы итеген балтырыннан тотып, сикереп торды.

Әбәкер, тиз генә үрелеп, бер читтәрәк яткан гайка ачкычын алды да Садабәкнең сукканын көтеп муенын җыерды.

Мин тәмам куркуга төштем. Бик яман хәл иде бу. Бер-берен үтерүләре ихтимал иде.

– Кирәкми, Әбәкер! Суга кермә! – дип яннарына йөгереп бардым. Аяк асларында бутала-бутала: – Кирәкми, Садабәк, бәйләнешмәгез! – дип ялындым.

Садабәк мине бер читкә этеп җибәрде, һәм шуннан соң алар, сугышырга җыенган ике юлбарыс шикелле, күзгә-күз терәп, тирмә эчендә әйләнеп йөри башладылар. Аннары икесе берьюлы сикерделәр дә, гайка ачкычы Садабәкнең башы янынннан ук сызгырып узды. Садабәк соңгы мизгелдә башын читкә алып өлгерде һәм ачкычны ике куллап тотып алды. Ләкин Әбәкер таза иде шул.

Шуннан соң алар көчәнә-көчәнә, сүгенә-сүгенә идәндә әүмәкләшергә керештеләр. Мин алар янына йөгереп килдем дә бөтен гәүдәм белән Әбәкер кулыннан төшкән ачкычка ташландым һәм, аны эләктереп алып, тирмәдән тиз генә чыгып киттем.

Судан кайтып килгән хатыннарны күреп:

– Әлдәй! Хәлифә! Тизрәк булыгыз! Сугышалар! Үтерешәләр... – дип кычкырдым.

Хатыннар чиләкләрен җиргә куйдылар да миңа таба йөгерделәр, тирмәгә килеп кергәндә, Садабәк белән Әбәкер әле һаман җирдә әүмәкләшеп яталар иде. Без тарта-йолка аларны көчкә аердык. Садабәк белән Әбәкернең киемнәре умырылып, үзләре канга батып беткән иде. Әлдәй ирен тирмәдән алып чыга башлауга, Әбәкер Хәлифәнең кочагыннан ычкынды да кычкырына-яный башлады:

– Кара аны, аксак эт! Каршыма тезләнеп гафу сорарсың әле, бетле хәерче, Әбәкернең кем икәнен белерсең әле!

Тәбәнәк кенә буйлы, ябык, юка гәүдәле Әлдәй Әбәкернең каршына килде дә туп-туры күзенә карап әйтте:

– Кулыңны гына тидереп кара! Күзеңне тырмап чыгарырмын! Үзеңне үзең дә танымассың аннары!

Садабәк сабыр гына бер хәлдә хатынын кулыннан җитәкләде дә:

– Ярар, куй, Әлдәй. Сүзеңне әрәм итмә шуңа... – диде.

Ул арада мин, тирмәдән чыгып, ызгыш вакытында ташлаган гайка ачкычын эзләп таптым, тирмәдән ераграк китеп, ачкычны таш сын янына күмеп куйдым. Шуннан соң җиргә утырдым да елап җибәрдем. Бөтен гәүдәм калтырана-калтырана, үксеп-үксеп еладым. Минем елаганымны беркем күрмәде, ни өчен шулай елаганымны үзем дә аңламадым. Янымдагы таш сын гына, минем кайгы-хәсрәтемә колак салган сыман, караеп торган буш күз чокыры белән усал итеп миңа карый шикелле иде. Тирә-якта арып-талып, тынып калган томанлы юеш дала җәелеп ята. Аның мәңгелектән килгән тирән тынлыгын шылт иткән тавыш та бозмый, бары тик мин генә күзләремне уа-уа сулыгып куйгалыйм. Шунда мин бик озак утырдым, кич җитеп, тәмам караңгы төшкәнче утырдым...

Менә шулай яшим инде мин аксыл-зәңгәрсу әремле гүзәл далада... Бөтен көчемне куеп тырышсам да, һаман әле эшнең җаена төшенеп җитә алганым юк. Менә әле тагын миңа Әбәкердән эләкте. Алга таба нишләргә инде, һич белгән юк. Ләкин күңелне төшерергә дә ярамый. Баскан җиреңдә нык торырга, аяктан егылганчы торырга кирәк.

– Әйдәле, бахбай, кызурак атла! Борын салындырырга ярамый безгә, кичеккәнне эш көтми...

2

Иртәгесен мин йокыдан иртәрәк, таң белән үк тордым. Кичен тирмәдә йокларга ятканда, мин «үлсәм үләм, әмма шундый итеп эшлим – мине сүгү-каһәрләү түгел, сүз дә әйтә алмасыннар» дип, күңелемнән карар кылган идем. Үземнең башкалардан бер дә ким түгел икәнлегемне күрсәтергә вакыттыр бит инде.

Беренче эш итеп тракторларга ягулык китердем, бакларны да үзем тутырып куйдым. Аннары, эш башланганчы радиаторларга су салыйм дип, мичкә белән чишмәгә киттем. Шуннан соң тамак ялгап алырга да яңадан, бер минутны да әрәм итмичә, су ташырга кирәк иде. Хәзергә эш мин исәпләгәнчә бара иде.

Ул арада инде аксыл томан баскан офык артында кояш та кыймылдый башлады. Ул, иксез-чиксез Анархай даласына күз салырга курыккан сыман, офык артыннан шактый озак чыкмый торды. Аннары гына күтәрелә төшеп, бер чите белән далага күз сирпеде. Иртә таңдагы дала өстеннән дә матуррак җир бар микән! Гүяки бөтен тирә-якка зур бер зәңгәр диңгез җәелеп киткән дә зәңгәр дулкыннары бер рәвешле катып калган – тик анда-санда гына куе яшел һәм сары урыннары күзгә чагылгалый.

Һай, Анархай, һай, олы дала! Ни уйлыйсың син, ник тынга калдың? Гасырлар буена нәрсәләр яшереп ятасың син, алда сине ниләр көтә?

Минем хәзергә әле су ташучы гына булуыма исегез китмәсен, мин әле шушы җиргә дә, машиналарга да хуҗа булачакмын. Безнең ике тракторыбыз һәм монда башкарган эшләребез әле эшнең башы гына. Мин кайдадыр укыган идем, тикшерүчеләр Анархай даласы астында бик зур җир асты сулары тапканнар, имеш. Ихтимал, ул әле, бәлки, тәгаен үк түгелдер дә. Ләкин ничек кенә булмасын, кешеләрнең бу җирне суга туендырачакларына, Анархайда яшел бакчалар шаулап утырачагына, салкынча арыклардан чылтырап су агачагына һәм мондагы җилләрнең алтын башакларны сыйпап исәчәгенә ышанам мин. Биредә шәһәрләр, авыллар калкып чыгар, безнең балаларыбыз бу даланы бәхетле Анархай иле дип атарлар. Бик күп еллар узганнан соң, бирегә минем шикелле үк бер егет килеп чыгар, аңа инде, әлбәттә, минем кебек, дала буйлап көнозын мичкә белән су ташып интегергә һәм берәр җүләрнең сүгенгәнен ишетеп торырга туры килмәс.

Тик шулай да ул егеттән көнләшмим мин, ник дигәндә, бу далага беренче булып мин килдем бит!..

Атымны туктатып, иртәнге дала өстенә күз салам. Бу минутта мин үземне дөньяда иң бәхетле, иң көчле һәм иң чибәр бер кеше дип хис итәм. Чыннан да бәхетле, рәхәт җир булсын Анархай!..

Ниһаять, офык артыннан, зур булып, нурланып-балкып, кояш чыкты.

(Дәвамы киләсе санда.)

(Дәвамы. Башы 35 нче санда).

Герой исемен алмаган 8 татар

Байков Зыя Рәхим улы 1919 елда туган, Казанның Бауман комиссариаты тарафыннан 1941 елның 14 октябрендә фронтка озатылган. 1942 елның 10 августыннан башлап Көньяк-Көнбатыш, Сталинград, Көньяк, 3 нче һәм 4 нче Украина фронтларында хезмәт итәргә туры килә, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. 4 нче гвардия укчылар дивизиясенең 11 нче полкында пулемет взводы командиры һәм гвардия старшинасы булып хезмәт итә.

1944 елның 3 декабрендә Байков взводы беренче булып дошманның Венгриядәге Элесаллаш саласы янында траншеяларга бәреп керә. Аннары яу ялкыны белән дошманның атакасын кире кага, алар эзеннән үзе ярсып дошман тылына бәреп керә, үзләренең чолганышта калу куркынычын аңлагач кына, янә совет гаскәрләре ягына дошман оборонасын өзеп чыга. Яу барышында Байков сугышчылары дошманның бер батальон солдатын, 2 йөк машинасын, 2 тубын, 15 пулеметын юк итә. Совет сугышчылары әле тагын дошманның 4 тубын, снаряд һәм патроннар складын, машина һәм пулеметлар, 120 венгр солдатын һәм 50 гә якын атны үз кулына төшерә. Херцер-Хальва станциясен, Киш-Вегим авылын эләктергән чакта Байков шәхсән үзе пулемет артына ята һәм яу тынганчы чигенми.

1944 елның 15 декабрендә Зыя Байковны Герой исеменә тәкъдим итәләр, эмма, гадәттәгечә, татар сугышчысы Кызыл Байрак ордены белән генә әппәр итеп куя.





Батталов Исмәгыйль 1913 елда туган, Юдино комиссариаты аша 1942 елның гыйнварында фронтка озатылган. Февраль аенда ук Көньяк-Көнбатыш һәм 1 нче Белоруссия фронтларында сугыша, авыр яралана. 16 нчы гвардия укчы дивизиянең 62 нче кавалерия полкында танкка каршы атучы булып яу йөри.

1945 елның 18 гыйнварында Польшадагы Пилица елгасын кичкәч, Исмәгыйль үз мылтыгыннан атып, дошманның 5 пулемет ноктасын, 19 немец солдатын һәм офицерын юк итә. Туктаусыз ут ачып, гитлерчыларның 2 танкын чигенергә мәҗбүр итә. 1945 елның 29 гыйнварында Радевитш бистәсе янында Фауге-Обра елгасын кичкәч, дошманның янә 3 пулемет ноктасын, 9 солдат һәм офицерын сафтан чыгара.

1945 елның 1 февралендә Исмәгыйльне Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр, ләкин бу татар да, гадәттәгечә, Кызыл Байрак ордены белән генә алдана.







Вәлиев Хөсәен Вәли улы 1907 елда Мамадыш районының Яңа Комазан авылында туган, шул ук районнан 1929 елның октябрендә Кызыл армия сафларына чакырылган. 1941 елның июнь аенда ук сугышчан бәрелешләрдә катнаша, Көнбатыш, Көньяк, 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтларында яу йөри. Авыр яралана, Александр Невский, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнергә өлгерә. 5 нче удар армиянең Сталин исемендәге 230 нчы укчы дивизиясендә, 988 нче укчы полкның 1 нче батальон командиры, майор дәрәҗәләренә ирешә.

Аның батальоны 1945 елның 23 апрель төнендә, иң беренче булып, Одер елгасын кичеп чыга, аннары Шпрее елгасын бик уңышлы кичә һәм Берлинның Трептов паркы янында немец оборонасын өзә. Шул вакытта батальон сугышчылары дошманның өч контрһөҗүмен кире кайтара, шулай итеп совет гаскәренең төп көчләренә юл арчый. Шушы Трептов паркындагы бәрелешләр вакытында гына да 153 гитлерчы солдат юкка чыгарыла, ә 1070 е әсирлеккә алына. Болардан тыш, Вәлиев батальоны хәрби корал белән шыплап тутырылган 27 тимерьюл составын кулга төшерә.

1945 елның 27 апрелендә Вәлиев Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, әмма яуның соңгы атналары бара, «юлбарыстан көчле» сугыша торган татарның бәясе төшкән инде, шуңа күрә аны гадәттәгечә Кызыл Байрак ордены белән генә йомалар. Ул 1989 елның 31 маенда вафат була һәм Мамадышта җирләнә.

(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.

«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

● Алинә Маликова һәм Тарас Стивкин.

НӘФИС СЫНЧЫ

Скульптор дигәч күпләрнең күз алдына, әлбәттә, көч-куәте ташып торган инсан килеп баса, чөнки бу һөнәр, чыннан да, сәламәтлеге нык булган, чиксез көч-куәтлеләр һөнәре генә кебек. Әмма әлеге иҗат өлкәсен күп очракта көч-куәте буенча әлләни аерылып тормаган хатын-кызлар да сайлый. Яшь скульптор Алинә Маликовага биргән беренче соравым да аңа һөнәр сайлау мәлен искә төшертте.

– Мин 1995 елда Казанда туганмын. Балачагым рәссамлыкка бик якын мохиттә үтте, чөнки әниебез Светлана Маликова – рәссам һәм тәҗрибәле курчак ясау остасы, ул «Әкият» татар дәүләт курчак театрында да эшләде, берара балалар өчен кызыклы иллюстрацияләр дә ясады. Әнием апам Альбинаны да, мине дә кечкенәдән рәсемнәр, курчаклар ясарга, төрле җәнлекләр әвәләргә өйрәтеп үстерде. Әтиебез Марат башка һөнәрдә иде, кызганыч, ул инде вафат.

Апам мәктәпне тәмамлагач, Н.И.Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесының дизайн бүлегендә укыды һәм реклама дизайны өлкәсендә 12 ел эшләде. Бүгенге көндә аның үз авторлык чәе остаханәсе бар. Ә мин 5 ел буе калабызның 6 нчы балалар сынлы сәнгать мәктәбендә белем алдым. IX сыйныфны тәмамладым һәм Н.И.Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесының дизайн бүлегенә имтиханнар тапшырырга юнәлдем. Шул көнне миңа: «Скульптура бүлегенә дә керә аласыз, сынчылыкка укырга теләмисезме?» – диделәр. Һәм шул бүлек аудиториясенә кердем. Анда сынчылыкка укып бетергән студентларның диплом эшләре тора иде, аларны карап чыктым да шундук нәкъ шушы бүлектә укырга булдым. Әниемне бу карарым бик гаҗәпләндерде, әмма мине беркем дә янә дизайнерлыкка үгетләмәде. Үз эчке сиземләвемә дә таяндым. Нәтиҗәдә, уку процессыннан бик тә канәгать калдым. Зур кызыксыну белән, һәвәсләнеп укыдым. Бу сәнгатькә күбрәк төшенгән саен, ул миңа шулкадәр күбрәк ошый барды. Безгә Татарстан Республикасының халык рәссамы, сынчы Асия Миңнуллина һәм сынчы мөгаллимә Зөлфия Мөхәммәтҗанова төпле белем бирде. Гомумән, Асия Минвәли кызының Казан сынлы сәнгать училищесы нигезендә узган гасырдагы скульптура бүлеген яңадан ачуга өлеш кертеп, укыта башлавын чиксез яхшы гамәлгә тиңлим. Менә миңа да туган калада, Казанда калып, шушы талант иясеннән гыйлем җыярга насыйп булды. Алган белемнәребез бәрабәренә югары уку йортына да керерлек дәрәҗәгә җиттек. Училищедагы диплом эшем рәссам-постимпрессионист Винсент Ван Гог сыны белән бәйле булды.

Бу уку йортыннан соң 2015-2021 елларда Мәскәүдәге Илья Глазуновның Россия сынлы сәнгать, сынчылык һәм корымчылык академиясендә укыдым. Академияне тәмамлаганда иҗат иткән диплом эшем «Амурның канатларын кисүче Сатурн» дип аталды. Аны шундый бер борынгы риваять буенча күзаллап, катлаулы композиция төзеп, персонажларның хәрәкәтләрен уйлап табып ясадым. Бүген мин Мәскәүдә яшәп иҗат итәм.

– Алинә, Мәскәү сезне киң иҗат мәйданы белән үзенә тартты, димәк?

– Әйе. Мин Мәскәү Рәссамнар берлеге сафына да кабул ителдем инде. Мәскәү каласы заказларга бай. Анда мәдәни чаралар, күргәзмәләр күп үтә. Үзеңнең сәләтләреңне күрсәтү өчен мөмкинлекләр күбрәк. Әлбәттә, әлегә мәшһүрлек казанган сынчылар җитәкчелегендәге күмәк төркемнәр составында эшлим. Моннан кала бүгенге көндә иҗади концепцияләрем буенча бер серия дә иҗат итәм. Билгеле, кайчан да булса үземнең монументаль хезмәтләрем дә булыр дип өметләнәм.

Гаять дәрәҗәдә куәтле, зур проектлардан 2019 елда 1942-1943 елларда Ржев янындагы Ржев-Вяземская операциясендәге коточкыч орышларда һәлак булганнарга, Совет Солдатына багышланган Ржев мемориал комплексы проектында катнаштым. Проектның авторлары – сынчы Андрей Коробцов һәм архитектор Константин Фомин. Шуны да ассызыклыйм: әлеге конкурста үтә тәҗрибәле сынчылар, халык рәссамнары, бихисап иҗатчылар катнашты бит, әмма иң яхшы образ эскизы шушы яшь сынчыныкы булып чыкты. Андрей

● Алинә Маликова. «Амурның канатларын кисүче Сатурн».

АЛИНӘ

● Алинә Маликова. «Киемле этюд».

● Алинә Маликова. Автопортрет. (Көзге белән).

Коробцовка ул вакыт – нибары утыз өч, ә Константинга утыз да тулмаган иде. 25 метрлы солдат сыны бронзадан коелды.

Минем җәмәгатем дә талантлы скульптор. Тарас Стивкин Әлмәттә туып үскән иҗатчы. Без Казанда да, Мәскәүдә дә бергә укыдык. Ул да бу зур проектны тормышка ашыруга өлеш кертте. Гомумән, ул чакта ил буенча илле сынчы җыелды, Совет Солдаты образы торна сыннары белән дә берләштерелеп бирелгәнгә күрә, барыбызга да эш җитәрлек булды.

Соңгы ел ярым вакыт эчендә ирем белән бергәләп хәрби рәссамнар студиясендә Россия Федерациясе Оборона министрлыгы заказы буенча 1812 елгы Ватан сугышы темасына багышланган горельеф иҗат итүдә катнашабыз. Әлеге проектның авторлары – сынчылар Людмила Семикопенко һәм Илья Гуреев. Берара сынчы Салават Щербаков остаханәсендә дә эшләп алдым. Шулай ук сынчы Ирина Макарованың да үз проектларына чакырганы булды. Мин – хезмәт килешүләре төзеп эшләүче ирекле скульптор. Һәм һәрбер хезмәт көнем тәҗрибә туплауга да барып тоташа...

– Тарасның да уңышлы иҗатыннан берәр мисал китерегез әле...

– Ул академик реализм стилендә дә, заманча, актуаль сәнгать юнәлешендә дә иҗат итә. 2020 елда ТАССР оешуга 100 ел тулу уңаеннан грант откан иде. Грант өчен без татар җирлеге белән бәйле берәр танылган шәхес образын сайлап алырга булдык. Озак кына уйландык. Нәтиҗәдә, Тарас Стивкин бронзадан «Тарихи җәмәгать эшлеклесе Б.Х.Мансуров» дип аталган сын койды. Сын сиксән биш см биеклектә. Ул ТР Мәдәният министрлыгына тапшырылды. Минем карашка бик тә уңышлы иҗат итте. Б.Х.Мансуров язмышы хакында шул мәгълүм: бу тарихи шәхес инкыйлабка кадәр дә кешеләр хокуклары өчен көрәшкән. Ә инде эшчеләр, крестьяннар һәм кызылармияче депутатларының республика съезды ачылып, ТАССР Үзәк башкарма комитеты оештырылгач, шушы комитетның 1 нче рәисе итеп сайланган булган. 1889-1942 елларда гомер иткән Борһан Мансуров ТАССР оешкан чорда, татарларны В.И.Ленин кабул иткән көнне дә С.Сәед-Галиев җитәкчелегендәге делегация составында булган. Республикабыз оештырылгач, аның нигезен ныгытуда да актив катнашкан. 1921 елның җәендә Мәскәүгә чакырылып, «Игенчеләр» бөтенроссия газетасы редакторы итеп билгеләнгән. Башка матбугат чаралары белән дә хезмәттәшлек иткән һәм яшь журналистлар тәрбияләү максатын да тормышка ашырган. Әйтик, Муса Җәлил дә аның укучысы булган дип раслана. Кызганыч, Б.Мансуров 1934-1937 елларда «Сугышчан алласызлар» журналының җаваплы редакторы эшен дә алып барган. Моннан кала Мәскәү предприятиеләрендә лектор-пропагандист буларак та чыгышлар ясаган. 1937 елда каты авырып киткән. Шулай да төшенкелеккә бирелмәгән. Бөек Ватан сугышы башлангач, аны Мәскәү өчен утын әзерләү максатыннан Мәскәү өлкәсенең Ведогущанск урман сәнәгате хуҗалыгына юллаганнар. Ул 1942 елның августында шунда вафат булган.

– Алинә, сез нәфис, нәзакәтле ханым, ә сынчылык шактый көч-куәт таләп итә. Төрле авырлыклар белән очрашмыйсызмы соң?

– Юк. Әлеге сәнгатьтә тырышлык күрсәтсәң, үз-үзеңә ныклы ышанычың булса, иҗат җиңел бара. Иҗаттагы бар процессларны да яратып башкарам, сыннар әвәләү миңа авырлык тудырмый. Ә металл каркасларга килгәндә, аларны миңа Тарас ясап бирә. Әлбәттә, дөрес итеп ясалган тотрыклы каркас – сынның ярты уңышы инде ул.

– Киләчәктә нинди темаларга иҗат итергә ниятлисез?

– Мин хатын-кыз хис-кичерешләре белән бәйле темага серия иҗат итә башладым. Шушы темада даими рәвештә булып, төрле образлар рәтен тулыландыра барачакмын.

– Алинә, әгәр дә сезгә татар башкаласында берәр скульптура композициясе куярга рөхсәт итсәләр, ул нинди хезмәт булыр иде?

– Без быел да Казанда игълан ителгән «Туган тел» скульптура ансамбле конкурсының I турында катнаштык. Аны Татарстанның Милли китапханәсе янәшәсендә урнаштырачаклар. Әмма әлеге тур бер иҗатчы өчен дә уңай нәтиҗә бирмәде. Шуңа күрә әгәр дә безне конкурсның II турына чакырсалар, көч сынашуыбызны дәвам итергә әзербез. Ана теленә багышланган һәйкәлләр бар, Татарстанда куеласы да матур, эчтәлекле булырга тиеш, дип саныйбыз.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

● Алинә Маликова. «Өйне сагыну».

● Алинә Маликова. «Йокысызлык».

● Тарас Стивкин әсәре. Тарихи җәмәгать эшлеклесе Б.Х.Мансуров.

АКТАНЫШ

(Дәвамы. Башы 33, 34, 35 нче саннарда).

Мәчти-Наратлы – әүвәл Бүләр, соңрак Байсар волосте составында исәпләнеп йөргән. Йөзбашы Мәсәгуть Абызаев җитәкчелегендә Байсарның үзеннән үк аерылып чыккан чакта, **1738** елның 9 сентябрендә төзелгән килешү нигезендә, мәчтилеләр Бәләбәй өязенең Шыгай авылыннан күченгән гаиләләрне дә кабул итә. Әмма Мәчти әйләнәсендә имана җире җитмәү сәбәпле, күчмәннәрне кире кайтып китәргә «үгетли» башлыйлар. Бу хакта килмешәкләрдән Габдерәхим Ракаев, Әюп Әбделманов, отставкадагы йөзбашы Габделхалик Шәрипов кул куеп, 1816, 1834 елларда «башкортлар» хокукын яклаучы Скарятиновка да мөрәҗәгать итә. Ләкин ахыр чиктә, авыл җыены карары белән, күчеп килүчеләрдән 8 гаиләне 1859 елда кире Шаран районындагы Шыгай авылына кайтарып җибәрәләр.

Сүз дә юк, әлеге низагъта 1811 елда Мәчти авылына хуҗа булып алган поручик Габделҗәлил Солтановның да кулы уйнамый калмагандыр. Чөнки күчмәннәр тәүге шикаять язган 1816 елда ук Мәчти авылын үз вотчинасына әйләндергән Солтановның бергә 26 туганы һәм аларның балалары килеп утыра. Бу нәсел саны 1859 елда 39 ир-атка җитә. Шул ук вакытта, 1859 елда бирәдә нигезләнгән «башкортлар» саны да 217 кешегә җиткән була инде. Хәтта әле 1912 елда да мәчтиләрнең 305 е – «асаба башкорт», ә 98 е «башкорт типтәре» булып исәпләнеп йөри (барлыгы 129 йорт).

Солтановлар нәселеннән мөфти Мөхәммәдияр Солтанов үсеп чыкканга күрә һәм аның тырышлыгы белән, 1877 елда Мәчтидә 25 ир балага исәпләнгән рус классы ачыла (Ә Иске Байсар авылында рус классы 1885 елда гына ачыла). Шул ук мөфти авылга кирпеч мәчет тә төзетә.

Меңнәр – Сөн елгасы буенда урнашкан, әүвәл Бүләр, соңрак Байсар волосте составында исәпләнгән. Беренче тапкыр 5 нче ревизия – 1795 елда гына телгә алына, улчакта 2 йортта – 15 «башкорт», 47 хуҗалыкта 156 типтәр, 1 йортта 4 татар яши. Аңлатмаларда типтәрләрнең Адай һәм Уръяды авылларыннан **1732** елда күчеп килүе ачыклана. Аларның бер өлеше Богады авылында да урын таба. 1816 елда «башкортлар» саны 42 гә җитә. 1870 елда инде 505 «башкорт» табыла. Ләкин 1912 ел халыкны 48 «башкорт», 773 типтәр дип искә ала. «Башкортлар» бу авылга аларның бабалары генерал Соймонов фәрманы буенча 1741 елда килеп утырган, дип бара. «Башкортлар»ның бер хуҗалыгына әле 1912 елда да – 55,6 дисәтинә, типтәрләргә 10,2 дисәтинә генә чәчүлек мәйданы туры килгән.

Мерәс – аны Байсар авылын тасвирлаган чакта ук искә алдык. Башкорт галимнәре исәпләгәнчә, авылга Байсарда яшәүче «башкорт» Мерәс Солтанаев **1730** елларда нигез салган булу мөмкин. Ул документларда Төкәй авылыннан Байсарга күчеп килгән Ирмәш Урмашевка һәм Бакалы районының Киләй авылыннан күченгән йөзбашы Мәсәгуть Абызаевка үз авыллары төзергә рөхсәт бирү уңаеннан телгә алына.

Шул ук елда Мерәс авылыннан Бикбай Уразов Әҗәкүл һәм Балтач вәкилләре белән бергә елына 23 әр сум хактан Әҗәк күлен Каракүл крестияннарына 12 елга арендага бирү турында килешүгә кул куя. Ә 1795 елда Мерәснең 17 йортында 104 «башкорт» исәпләнә. 1905 елда халык саны 520 кешегә җитә.

Сасыборын (Елгабаш) – Бүләр волостеның Бүләр түбәсенә карый, элек Ык елгасы бормаланып аккан һәм Сасыборын елгасы килеп кушылган тарлыкта нигезләнгән. **1600** елларда ук тарихи документларга кергән. 1795 елда ук 19 йортта 160 «башкорт» яшәве ачыклана, димәк ки, авыл ким дигәндә 50 ел элек гомер сөргән инде. 1905 елда 190 хуҗалыкта яшәүче халык саны 966 га җиткән. Әмма 1960 елларда Түбән Кама ГЭСы төзелә башлау сәбәпле, авыл Мөслим районына күчерелгән һәм Елгабаш исемен алган. Ни кызганыч, яңа урында йорт-хуҗалыклар да санаулы гына шул...

Иске Сәфәр – Бүләр волостеның Бүләр түбәсенә буйсынучы авыл, Терпеле һәм Бөят Бавы елгалары буена урнашкан, 11 (1847 елдан соң – 12) нче «башкорт» кантонының 1 нче йортына карый. Тәүге тапкыр 1795 елда гына җанисәп үткәрелә һәм авылның 17 хуҗалыгында 166 «башкорт» яшәве ачыклана. Ләкин тарихы тирәндәрәк.

1842 елда Сәфәр вәкиле Хәйбулла Әхмәров әүвәл Башкорт-мишәр гаскәре башлыгына, аннары стряпчий Скарятиновка авылны нигезләүче бабалары кулына **1653** елда бирелгән вотчинниклык грамотасын китереп сала (ул архивта «эзсез югала», ә ул грамотаны алу өчен Бүләр авылы старшинасы Байсар Кузәшев та аз көч куймый). Бераздан тәүге грамотага яңа аңлатулар өстәлә. Грамота Байсар Күзәшев үз биләмәсенә яшәргә керткән Айтуган Сабаков кулына тапшырылган булган һәм сәфәрләр аның буенча сусар тиресе һәм бал белән ясак түләп яшәгән. Авылның 1703-1745 елларда түләгән 47 данә квитанциясе дә сакланган. Ләкин алары да, грамотаның үзе шикелле үк, юкка чыккан. 1854 елда 12 нче «башкорт» кантоны башлыгы хорунжий Солтановка аңлатма биргән чакта сәфәрләр үз бабаларының Чалманарат авылыннан күчеп килүе һәм аларның бердәнбер вотчина хуҗасы булуы турында бәян итә.

Шулай ук, Сәфәр авылы XVII гасырның II яртысында, Йәнәй волостен яңа түбәләргә бүлгән чакта, Богады түбәсендәге авыллар рәтендә санап үтелә («Аулы...», 26 бит). 1785 елда сәфәрләрнең Кадермәт, Байсар, Ахун, Сәет, Елан авылы вәкилләре белән бергә Бөгелмә һәм Минзәлә өязләренең Зәй, Урсала, Шәрләмә, Ирнә, Ямаш елгалары буендагы вотчина җирләрен 700 сум бәядән граф А.К.Разумовскийга сатып җибәрү актында катнашуын да әйтергә кирәк. Аннары Сәфәр вәкиле Гаделша Айдагулов һәм күрше авыллардагы 9 вәкил 1802 елда Күҗәкә авылында туып үскән поручик

● Актаныштагы «Адымнар» мәктәбе бинасы.

Габделҗәлил Солтановны 500 сум «ришвәт» түләү хакына Мәчти авылында яшәргә кертүче килешүгә дә кул куйган.

Сәфәр авылында 1812 елгы Ватан сугышында һәм Парижны яулауда катнашкан һәм ике көмеш медальгә лаек булган Корбангали Бикташ улы Туктаров гомер иткән. Авылда иң тәүгесе 1837 елда ук ачылган 3 мәдрәсә эшләгән. 1912 елда 315 йортта 1572 «башкорт» гомер иткән. Гаҗәп, алар да әле һаман бәрәңге утыртмаган.

Яңа Сәфәр – Йәнәй волостеның әүвәл Байсар, аннары Өшәр түбәсенә кергән. Авыл вәкиле **1757** елда Апач, Байсар, Өшәр, Суыксу, Шәбез, Әҗби кешеләре белән бергә Агыйдел буендагы балыклы урыннарны елына 20 шәр сум түләү хисабыннан Каракүл крестияннарына 20 еллык арендага бирүдә катнашкан. 1795 елда авылда 260 «башкорт» һәм 39 типтәр гомер иткән. 1798 елдан соң 11 нче башкорт кантонының 14 нче йорты составына кергән. Ләкин шул 1795 елдан соң авыл мантып китә алмаган, халык саны кими башлаган. 1902 елда 55 кенә кеше калса да, 1912 елга кадәр кабат үсеш башланган һәм халык саны 231 кешегә җиткән.

Солтангол – Йәнәй волостеның Богады түбәсе составында, Сарсаз елгасы буена урнашкан авыл. Аны Байлар волостеның Салагыш түбәсенә караучы авыл халкы нигезләгән. Солтангол XVII гасырның II яртысында, Йәнәй волостен яңа түбәләргә бүлгән чакта, Богады түбәсенә буйсыначак авыллар рәтендә саналган. 1795 елда 15 йортта 164 «башкорт» яшәгән. 1816 елда «башкортлар» саны 227 гә җиткән. Алар арасында авылга нигез салучы Солтанголның улы Усай да телгә алына. 1816 елда шушы авылда гомер итүче Вәлит Мортазин Солтанголдагы тәүге бабайларның Салагыш түбәсеннән вотчинниклык грамотасы буенча 1724 елда, 82 ир-ат күләмендә күчеп утыруын искә ала. 1742 елда Солтангол Сөрмәтев Йәнәй волосте старшинасы Ярмөхәммәт Ибраевны авылларга килеп, «башкорт» йортларыннан ат, сарык, көбә (панцирь), хатыннарның диңгез кораллары белән бизәлгән баш киемнәрен талап һәм үзен воевода дип атап йөрүенә каршы чыккан.

1912 елда авылда инде 1025 типтәр исәпкә алынса да, 37 хуҗалык утарында бернинди терлек тә тотылмый, 202 өйнең бер йөзе атсыз, 62 хуҗалык сыерсыз интегә.

Суыксу – Йәнәй волостеның Камбарка түбәсендә исәпләнә. Бу авыл «башкорты» Сәфәр Габдуллин 1745 елда Саклау күлен Марьино авылы крестияннарына 12 елга арендага бирү уңаеннан төзелгән килешү кәгазендә телгә алына. Чыннан да вотчинник булганга күрә, алар соңрак Сагадак күлен арендага бирүдә дә катнаша.

Вотчина грамотасын **1638** елда ук Йәнәй волостендагы Суыксу авылы «башкорты» Җамали Ядегәрев һәм аның иптәшләре алган була. Җамалиның исеме 1663 елда төзелгән бер документта да телгә алына (История башкирских родов. Гирей. 86 бит). Әлеге Җамали үз шикаятендә рус кешеләренең аның вотчинасындагы инешләр буена куелган чолыкчылык ояларын җимереп йөрүе, Сагадак күлендәге балыкны һәм сусарны рөхсәтсез тотуы, ә үзенә шушы таланган вотчина өчен дә ел саен казнага 30 сусар тиресе һәм 11 батман бал түләп баруы турында бәян итә. 1669 елда Уфа воеводасы Федор Сомов Йәнәй волосте вәкилләре булып килгән «башкорт» Борис (Барый-?) Биздергәнов, Онтошка (?) Бисарин һәм Уркенечка (Иркәнәш-?) Чирмешевкә Кама елгасының ике ягында да бабаларыннан калган җирләре, күлләре, хәтта елга уртасында утраулары да булу турында грамота язып бирә. Ләкин хәл «башкортлар» файдасына хәл ителми, күрәсең. 1700 елда Жденко (?) Асылов белән Ингел Ядегәров инде Петр патша исеменә шикаять язып җибәргәннән соң гына, аларга яңа грамота бирелә...

Ә 1795 елда авылның 27 йортында 197 «асаба башкорт» исәпкә алына. 1929 елда 178 хуҗалыкта 929 «башкорт типтәре» гомер итә. Семиостров волостеның идарә йорты шушында урнашкан була, авылда 5 җил тегермәне, 3 кибет эшли. Татарстанның Тукай районындагы туган як тарихын өйрәнүчеләр «Татар Суыксуына XVIII гасырда Чаллы янындагы Куады белән Оргыды авылы татарлары да күчеп утырган, тәүге чорда Суыксуның ике урамы Куады һәм Оргыды исемен дә йөрткән», дип белдерә.

Табынлыкүл – Бүләр волостеның әүвәл Бүләр, аннары Әмәкәй түбәсендә исәпләнгән авыл. Ул **1772** елда Солтанморат Колмәтев белән Искәндәр Әлмәтевнең Калмия елгасындагы тегермән урынын Торай (Торачы-?) авылы кешесе Бикәй Биктимеровка 17 сум хактан сатып җибәрүләре уңаеннан телгә алына. 1795 елда тәүге ревизия үткәрелә һәм авылдагы 9 йортта 77 «башкорт» яшәвен ачыклый. 1912 елда 118 хуҗалыкта 650 кеше гомер итә.

Такталачык – Гәрәй волостеның түбә үзәге. Авыл тарихи документларда тәүге тапкыр **1631** елда искә алына. 1832 елда үткән Генераль межалау барышында

АВЫЛЛАРЫ

Такталачык авылына тәүге җир саклау грамоталарының 1691 елда бирелгән булуы ачыклана. 1700, 1701 елларда Уфа воеводасы Борис Аничков Такталачык «башкортлары» Хуҗамәт Бикмәтев белән Ишкенә Тимкәевкә Юкәле, Ямалы, Сөтле, Шәбез, Бажы, Кабан (Краснокама районында), Ямады (Яңавылда) һәм тагын берничә инеш һәм күл буендагы вотчиналары булуны раслап грамота бирә, шунда ук әлеге вотчиналарга аларның ата-бабалары ук хуҗа булып торуын искәртергә дә онытмый. Шуңа карамастан, такталачыклылар 1729 елда үз вотчиналарына янә бер мәртәбә грамота алуга ирешә.

1740 еллардан соң такталачыклылар тормышы тулысынча диярлек Мутиннар исеме белән бәйләнеп бара. 1743 елда бирегә этисе Сарман районындагы Җанырыс авылын нигезләгән Җанырысның улы Мөтә күчеп килә. Мөгаен, ул үтә гадел дә, гади крестияннар өчен җан ата торган старшина да булмагандыр. Шул 1743 елдан соң ук власть иярләренә Мөтә өстеннән бик күп шикаять юллана. Әйтик, Гәрәй волосте «башкорты» Үтәгән Ичибаев (Илчебаев-?) аны вотчинага рус крестияннарын кертүдә дә, законсыз рәвештә алардан оброк җыюда, балык тоту урыннарыннан һәм вотчинник булудан файдаланган өчен 300 хуҗалыктан 120 сум акча, 20 пот чикләвек, 2 пот йон, 100 аршин тукыма җыюда да гаепли.

Әүвәл йөзбашы, аннары этисе урынына старшина булып калган Тимер Мутин 1757 елда Пруссиягә каршы башланган Җидееллык сугышта «башкорт» командасы башлыгы Кыдрач Муллакаевның ярдәмчесе булып катнаша. 1759 елда ул патшабикә Елизавета Петровнага тугрылык белдерү өчен мөселман делегациясе составында Петербургка да бара. Шушы өстенлеккә ирешүдән файдаланып, Сенатка башкорт вотчиналарына сәүдәгәр һәм завод хуҗаларының рөхсәтсез керүе, җирләрне тартып алуы турында шикаять язып бирә. Ни галәмәт, Сенат шундук Уфа өязенә һәм Оренбург канцеляриесенә башкорт җирләрен талауны туктату турында ашыгыч фәрман юллый. Әмма Тимер үзе әлеге шатлыклы хәбәрне ишетергә өлгерми, Петербург каласында чакта ук вафат була.

Тимернең улы Атнагол, шулай ук, Гәрәй волосте старшинасына әверелә. Әмма ул «падишаһ Петр Федорович хәзрәтләре» гаскәренә кушыла һәм 1774 елның гыйнвар аенда Алабуганы камалышка алуда катнаша. Шул елның 17 октябрендә власть иярләре каршына баш иеп килсә дә, аны тотык итеп төрмәгә ыргыталар. 1798 елдан соң ул 11 нче «башкорт» кантоны башлыгы булып тора. Атнаголның 8 улы да төрле вакыйгалар агышында йорт башлыгы, йөзбашы, походный старшина, кантон башлыгы ярдәмчесе, яу походлары барышында йөзбашы, урядник, хорунжий да булып йөри, ягъни өстенлекле хәлне берсе дә кулдан ычкындырмый. Аларның нәселе тора-бара Оренбург губернасының дворяннар исемлегенә дә кертелә.

Әлеге нәсел дәвамчыларының берсе – 1888 елда туган Илдархан Мутин 1917 елның июлендә азат Башкортстан республикасын төзү өчен көрәшкә кушыла. Ул Үзәк Башкорт шурасы әгъзасы булып та сайлана, декабрь аенда республика игълан ителгәч, Башкортстан хөкүмәте, хәрби-революцион комитет әгъзасы, Хәрби шура рәисе урынбасары, финанс бүлеге башлыгы, эчке эшләр, социаль-тәэминат комиссары, азык-төлек бүлеге халык комиссары булып та сайлана. 1920 елның июнендә Мәскәүдәге совет хөкүмәте Башкортстанны автономия кысаларына куып кертә башлагач, Урта Азиягә чыгып качарга мәҗбүр була, ләкин бераздан кире әйләнеп кайта. 1938 елда аны кулга алалар һәм атып үтерәләр...

Мутиннарның тагын бер данлыклы улы Мохтар гомерен театр тормышына багышлый, башка беркем дә булдыра алмаганча Отелло ролен башкара. Аны 1920 елларда «яңадан директоры итеп сине куячакбыз», диген ялган вәгъдә белән Башкортстан районнарына акча җыярга озаталар. Ул бик күп мая җыеп кайтса да, директорлыкка Кәрим Тинчурин сайлана. Мохтар янә Уфага китәргә һәм берничә ел буе бүгенге М.Гафури исемендәге театрны формалаштыруга катнашырга мәҗбүр була. Яңадан Казанга әйләнеп кайта-кайтуын, әмма аны да нәселдәше Илдархан Мутин язмышы көтеп тора. 1940 елда аның да гомере төрмәдә өзелә. Ни кызганыч, район үзәге яки Казан урамнарының берсенә дә атаклы Мутиннар нәселенең исеме бирелмәгән. Аларга багышланган музей-һәйкәлләр төзергә дә җыенып йөрүче юк...

● Кормаш авылында туып үскән атаклы рәссам һәм сынчы Зилфәт Басыйров.



● Кормаш авылында мәгърифәтче Әхмәтхафиз Дәүләтьяров истәлегенә куелган хәтер тактасы.

Теләкәй – Шәбез елгасы буенда, Гәрәй волостеның Такталачык түбәсендә саналучы авыл. Аны **1650** еллар тирәсендә ун мең дисәтинә җиргә һәм ун мең баш елкыга хуҗа булып гомер иткән атаклы Теләкәй морза Улакаев нигезләгән булуына тамчы да шик юк. Татар энциклопедиясе аны 1729 ел тамгасы куеп кына искә ала. Гаҗәп түгел, кабинеттан чыкмый утырган «галимнәр» Иске Байсар авылын да – 1713, Минзәлә районындагы Бикбау авылын 1729 елгы, дип кенә «мөһер» суга. Ә без фәкыйрегез Бикбау авылы янындагы тәүге зираттан авылны нигезләүче Бикбауның улы Йосыф истәлегенә 1657 елда куелган ташны эзләп табу бәхетенә ирештек. Алда әйтелгәнчә, Байсар авылы да 1570 елда ук «чәчәк» аткан инде. Теләкәй морза да 1684 елда ук дар агачына асып үтерелгән. Ул – хәерче түгел, ә Габдулла хан-Карабәк нәселеннән. Шундый затлы морза үзе исән чагында ук утар кормый, авыл нигезләми яши аламы соң?! Актаныштагы Теләкәй түгел, хәтта Илеш җиренә күченгән Теләкәй авылы да 2019 елда үзенең 300 еллык бәйрәмен билгеләп үтте ләбаса!..

Теләкәй авылы тарихи документларга 1744 елда гына, Мерәс, Әҗәкүл, Актанышбаш кешеләре белән бергә үз авылларының вәкиле Биккенә Күчеков тарафыннан Әҗәк күлен елына 30 сум табыш исәбеннән Каракүл крестияннарына 10 ел арендага бирү уңаеннан килеп эләгә. Халык ач яшәми. Иген игү, терлек асраудан тыш, Теләкәй ирләре Пермь губернасына утын кисәргә һәм ярырга йөреп тә, аена 4-5 тәңкә акча эшли.

1912 елда авылдагы 131 йорттә 630 «асаба башкорт» яшәве ачыклана.

Тыңламас – Кыргыз волостеның Сөн тамагы янында утырган иң борынгы авылларның берсе. Әлеге авылдан Баулы, Ютазы, Туймазы, Бәләбәй чикләренә чаклы сузылган вотчинаның 1467-1479 еллар аралыгында ук Ибраһим хан тарафыннан Котлымөхәммәт Котлыгышев атлы бигә бүләк ителгән булуы хакында алда әйттек инде. Һич тә нигезсез түгелдер, Бөгелмә өязендәге Кызылъяр авылында яшәгән һәм Пугачев фетнәсе чорында үз биләмәләренә грамоталарын югалткан кыргызлылар 1802 елда кире Тыңламас авылына әйләнеп кайта («Аулы...» – 428 бит).

Авылны нигезләүчеләрнең властька яңа, урыс хакимияте килгәч тә, үз вотчиналары өчен **1659** елда ук грамота алулары билгеле. 1795 елгы ревизия Тыңламаста 13 «асаба башкорт», 48 «башкорт типтәре» һәм 165 типтәр яшәвен ачыклый. 1912 елда анда 96 «башкорт» вотчиннигы, 675 типтәр яши.

Тайморза (Түмерҗә) – Гәрәй волостеның Такталачык түбәсенә карый. Теләкәй авылыннан аерылып чыгып нигезләнгән, дигән фараз да бар. 1795 елда 15 йортта яшәүче 65 «башкорт» вотчиннигы исәпкә алына. Әмма авыл инде **1754** елда ук тарихи документларга эләгә. Бу чакта Тайморза, Җияш, Теләкәй, Такталачык ирләре Борындык (Карга) күлен Каракүл крестияннарына 10 елга арендага бирү турында килешү төзи. 1831 елда бу авылдан хорунжий Әхтәм Кинҗәкәй улы Уразмәтов офицер лаек була һәм дворяннар сафын тулыландыра.

1912 елда авылда 291 «башкорт» вотчиннигы гомер итә.

Тупач – Минзәләдән 15 чакрымда гына урнашса да, элек ул Кыргыз волостеның Ябалак түбәсенә карый. 11 нче «башкорт» кантонының 9 нчы йорты составында исәпләнә. 1834 елда авыл 20 «башкорт» вотчиннигыннан һәм 100 «башкорт» типтәреннән хасил була. Соңыннан типтәр һәм татар авылына әверелә.

Түке – Бүләр волостеның Мөшегә түбәсе составында, Бәҗәнә елгасы буенда. 1795 елда гына ревизия үткәрелә, анда 22 «башкорт», 160 типтәр яшәве ачыклана. Бүләр волосте вотчинникларына үз җирләренә типтәрләрне кертү хокукы турында грамота 1683 һәм 1701 елларда ук бирелә. 1727 елның көзендә булып узган хәлләр бик гыйбрәтле. Моңа кадәр Уразмәт авылында гомер иткән Түке Ибаев (Ибраев, Гобәев-?) атлы мари (?) типтәре Мәсәгуть авылында яшәүче Мәсәгуть Тәтимов белән Уразмәт авылы «башкорты» Әлмәт Атнагуловка сыер, тана һәм бер бозау, чолыкчылык ояларын 6 тәңкәгә «сатып» җибәрә дә, тегеләрдән Шәбез елгасы буенда вотчина җирләренә кереп урнашырга, анда чолыкчылык ояларын җаелдерергә рөхсәт ала. Менә шул 1727 елны һәм Түке Ибаевны авыл туган ел һәм аны нигезләгән кеше дип исәпләү бик урынлы.

Югарыда исеме телгә алынган Мәсәгуть Тәтимов 1730 елларда Бүләр волосте старшинасына әверелә, ул 1735-1738 елларда Акай Күчемов җитәкчелегендәге милли-азатлык явында катнашкан өчен Себергә сөрелгән бүләрлеләрнең вотчиналарын үзләштерүдә, казнага ясак җыйганда 50 сумга якын байлыкны яшереп калдыруда гаепләнә һәм Себергә сөрелә. Аның урынына Исламгол Аккуҗин атлы яңа старшина билгеләнә. Ләкин күп тә үтми, Мәсәгуть Тәтимов хәтта сөргеннән качып кайта һәм якташларын яңадан талый башлый. Власть иярләре аны янә кулга алып, Себергә сөрергә мәҗбүр була.

Түбән Яхшый – әүвәл Бүләр, соңрак Байсар волостенда. 1795 елда да исәпкә алынмый. 1816 елда 17 ир-ат яши. Әле 1905 елда да авыл Олы Имән Тамагы дип йөртелгән, 1912 елдан соң Яхшый. 1912 елда 230 «башкорт» вотчиннигы, 50 типтәр яшәгән, дип исәпкә алына.

Югары Яхшый – Бүләр-Байсар волосте составында, Олы Имән һәм Сикия елгалары буена урнашкан. Документларда **1730 елларда** телгә алына. 1795 елда биредәге 12 йортта 89 «башкорт», 15 типтәр яшәгән, дип санала. 1816 елда үткәрелгән ревизия вакытында моңа кадәр Йәнәй волостеннан Бүләр волосте җирләренә килгән байтак крестияннарны законсыз күченгән, дип таныйлар һәм авыл икегә – Югары һәм Түбән Яхшыйга бүленә. 44 ир-ат – Югары, ә 12 ир-ат Түбән авылда исәпләнә. Ике авыл уртасында, тау астындагы тигез яланга урнашкан бер урамлы авылны берара Казгалак дип тә йөртәләр, ул 1735 елгы документларда телгә алына.

Яхшый авыллары тарихи документларга 1792 елда да килеп эләгә. Ул чакта Бүләр волостен Муса Мөслимов (Пугачев явында да катнашкан старшина бу!) җитәкли. Яхшый авылындагы 4 хуҗалык иясе Уфа наместничествосына 500 йорт башлыгы Бикташ Пулатов кул астында булган Бикчәнтәй авылы авылы типтәрләре Габбас Зәетов, Гайсә Зәетов, Морат Ишкинин һәм шушы ук округтагы Йәнәй волосте старшинасы Гаделша Әрәпталовка буйсынган Каентүбә авылыннан «башкорт» Әҗмәкәй Әҗмәтевне 70 еллык шарт белән яшәргә кертү һәм ел саен алардан 25 сум 70 тиен акча җыю турында үтенеч юллый.

1912 елда Югары Яхшыйда 475 «асаба башкорт», 69 типтәр гомер итә.

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

Каллиграф, мөгаллим Мөхәммәтгали Мәхмүдов

XIX йөз урталарында Казан университетында татар милләтеннән булган һәм югары белем алмаган бердәнбер мөгаллим, шуның өстенә крестьян сословиясеннән Гали Мәхмүдов гаять әһәмиятле эшне башкара – ханнар заманыннан килсә дә, Казанны алу белән юкка чыга язган матур язу сәнгатен кайтаруның башында тора.

Мөхәммәтгали Мәхмүдов Казан губернасының Минзәлә өязендәге Сәләнгүр авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Казанның Зәңгәр мәчете мәдрәсәсендә белем ала. Мәдрәсәләрдә матур язу – каллиграфия сәнгатенә дә өйрәтәләр. Бу һөнәрдә бүтән шәкертләр арасында алга киткән Гали Мәхмүдовны Казан университеты җитәкчелегә күреп ала.

Университетта 1840 елда шәрык факультеты ачылган була бит. Патша Казанда шәрык телләрен өйрәтеп татарны белемле итү, тамырларын ныгыту максатын куймаган, билгеле. Татарны руслаштыру сәясәтен алып барган хакимияткә шәрык факультеты ачу нәрсәгә кирәк булган соң? Шәрык илләренә әзерлекле вәкиллекләр, дипломатлар юллап, дәүләт сәясәтен алып бару максатында башкарылган эш бу. Ләкин шәкертләргә белем бирү өчен китаплар, дәреслекләр кирәк. Мәдрәсәләрдә исә шәкертләр шәрык әсәрләрен, дәреслекләрне күчереп яза. Шуңа күрә университет җитәкчелеге, аерым алганда, Казанда шәрык мәктәбенә нигез салучыларның берсе Александр Казембек мәдрәсәләр белән гел элемтәдә тора. Ул 1812 елгы Ватан сугышында катнашкан, отставкага чыккач исә Казан уку-укыту округының попечителе булган Михаил Мусин-Пушкинга татар, гарәп, фарсы телләрен белгән оста каллиграф Гали Мәхмүдовны мөгалимлеккә алу тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә. Әмма крестьян сословиясеннән булганга һәм аларга үзләре теләгәнчә күченеп йөрү иреге бирелмәгәнгә күрә, Г.Мәхмүдов 1844 елда гына университетта эшләп китә.

Каллиграфия университетта дүрт ел дәвамында өйрәтелгән. Университетка барганда Г.Мәхмүдов комиссиягә үзенең язу үрнәкләрен тапшыра. Шулардан бүген архивларыбызда өч кәгазь бите сакланган. Язу үрнәкләренә карап, Мәхмүдовның язу серләрен генә түгел, шәрык илләрендә киң таралган әдәби әсәрләрне күчереп язу кагыйдәләрен дә яхшы белгәне турында нәтиҗә чыгарырга мөмкин.

Казан профессорлары Мөхәммәтгалидән бик канәгать була. Александр Казембек, мәсәлән, аның укытуда фидакярлеген, билгеләнгән сәгатьләрдә генә түгел, шәкертләр белән өстәмә дә шөгыльләнүен, кәгазь, кара, буяу, камыш-каләм һ.б. кирәк-яракларны укучылары өчен үзе табуын билгеләп үткән.

Сәнгать белгече Петр Дульский үзенең хезмәтендә биограф П.Траубенбергнең Гали Мәхмүдовның вафаты уңае белән язылган некрологын китергән. Аннан Мөхәммәтгалинең холык-гадәтләрен чамаларга була. «Мәхмүдовның матур гадәтләре игътибарга лаек иде. Мәрхүм рухын камилләштерү өчен тырышты. Әйләнә-тирәдәге кешеләргә карата йомшак, нәзакәтле, үзенә карата һәрвакыт каты, аяусыз булды. Мал җыймады, аздан гына да канәгать була белде. Үзе текте-ямау салды, аяк кименәре ясауны, агач, тимер эшен белә иде. Татар укытучылар мәктәбенең инспекторы вазифасыннан киткәч, өйдәге бөтен шкаф-караватны кешеләргә таратып, үзенә яңаны ясады. Буш вакытларында матур итеп скрипкада уйнады. Беренче гимназиядә эшләгәндә һәм аннан соң отставкада, татар укытучылар мәктәбенә инспектор итеп билгеләнгәнчегә кадәр 25 еллап гел бер кечкенә һәм тар фатирда яшәде. Үзенә ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләрне исә бервакытта да кире борып чыгармады, кулыннан килгәннәрнең барысын да эшләргә тырышты. Казанда басылган шәрык китапларын уку-төзәтү белән күп шөгыльләнде. Авыр эш булуга карамастан хезмәте өчен бер тиен алмады. Шулай итеп кирәкмәгәнгә акча сарыф итмичә яшәсә дә, байлык тупламады...»

● Кызы Бибигайшә Терегулова.

● Хатыны Гөлчирә һәм кызы Бибигайшә белән.

Ошбу тасвирнамәне укыгач, юаш һәм тыйнак мөгаллим күз алдына килеп басарга мөмкин. Әмма Мөхәммәтгали кайбер мәсьәләләрдә үҗәт һәм катгый, үзсүзле дә була белгән. Мәсәлән, университеттан соң беренче гимназиядә эшләгәндә ул уку йортының җитәкчесенә татарча тегелгән кием кияргә һәм сакал йөртергә рөхсәт сорап хат яза. Университетта укытканда да хәтта милли киемнән йөрдем, дип өсти. Әмма Мәхмүдовка үзебезчә киенергә рөхсәт итмиләр. Шулай да аның 60 яшьләрендә төшкән сакаллы портретына караганда, Мөхәммәтгали сакал мәсьәләсендә булса да үз дигәненә ирешкән булса кирәк.

Югарыда искәртеп үтелгәнчә, 1855 елда Шәрык факультеты Санкт-Петербурга күчкәч, Мөхәммәтгалине башкалабызның 1 нче гимназиясенә мөгаллим итеп билгелиләр. Соңыннан Мәхмүдов гимназиянең директоры була. Татар һәм төрек телләрен укыту буенча дәреслекләр яза. Аннары фикердәшләре белән татарда беренче дөньяви уку йорты – татар укытучылар



● Мөхәммәтгали Мәхмүдов.

● Оныгы, беренче татар артисткаларының берсе Хәлимә Терегулова.



● П.Дульскийның Г.Мәхмүдов турында китабы һәм каллиграфның язу үрнәге.

мәктәбен ача. Аңа беренчеләрдән булып Шакирҗан Таһиров атлы милләттәшебез укырга керә. Мәхмүдов Шакирҗанның рәсемгә сәләтен күреп, аны үстерү өчен тырыша. Нәтиҗәдә, Ш.Таһиров татарлардан беренче булып татар мәктәпләрендә рәсем дәресе укытырга рөхсәт ала. Аны татарлардан чыккан беренче рәссамнарның берсе, дисәк тә хата булмас. Шакирҗан да остазы Мөхәммәтгали кебек татар һәм төрек телләрен укыту буенча дәреслекләр яза. Аның улы Фаик исә Казан сәнгать училищесында белем алып 1920 елларда үзен талантлы график итеп таныта. Мәхмүдовның зирәклеге, талантларны вакытында күрә, үстерә белүе, киләчәкне, милли тормышны кайгыртып яшәве нәтиҗәсендә, татар дөньясы әнә шундый талантларга ия булды.

Мөхәммәтгали соң өйләнә. Хатыны Гөлчирә белән Мөхәммәдьяр исемле бер ир-бала һәм Бибигайшә атлы бер кыз тәрбияләп үстерәләр. Бибигайшә күренекле җәмәгать эшлеклесе, мөгаллим Ибраһим Терегуловка кияүгә чыгып биш кыз дөньяга китерә. Шулар арасыннан Хәлимә Терегулова татар театр сәнгатен барлыкка китерүчеләрнең берсе була, беренче татар спектакльләрендә катнаша. Шуңа өстәп, ул – Мәскәү консерваториясен тәмамлаган татарлар арасында музыка буенча профессиональ белем алган беренче хатын-кыз да. Озак еллар Казанда төрле музыка уку йортларында, шул исәптән консерваториядә музыка белгече булып эшли. Казан рәссамы Павел Беньковның мәшһүр «Кәләш» картинасында нәкъ менә Хәлимә Терегулова сурәтләнгән. Мөхәммәтгали Мәхмүдовның бүтән оныклары да мәгърифәт юлында күп көч куя. Әминә Казан университетының медицина факультетында белем ала, Мәдинә Троицкида, Касыйм шәһәрендә татар мәктәпләрендә укыта, Рәбыйга Казан университеты каршындагы Лобачевский исемендәге атаклы китапханәдә эшли, Фатыйма биологка укый, Бөгелмәдә укыта...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА
әзерләде.

Петр Дульскийның «Казанский каллиграф Али Махмудов (Очерки по истории Востоковедения Казанского университета» китабы, галимә Фирдәвес Ваһапованың «Творческое наследие Али Махмудова» мәкаләсе («Эхо веков» журналы), туганы Рөстәм Заһировның «Миллиард Татар» басмасыннан «Первый каллиграф: как татарин Мухаммад Махмудов покорял Казанский императорский университет» язмасы, «Из родословной «Татарской невесты» мәкаләсе (Ш.Мәрҗани институтының «Татарский мир» каналы) файдаланылды.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәваланугa керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

16 сентябрь (шимбә). ***Рабигүл әүвәл аеның 1 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 7.12 сәгатьтә калка, 19.11 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.45 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Йөрәккә дәва (1)

Дүләнә чәчәге һәм җимеше йөрәк мускулының тонусын күтәрә, коронар тамырларда кан әйләнешен көчәйтә. Тигез микъдарда кушылган чәчәк һәм җимешләрнең 3 аш кашыгын 3 стакан кайнар суга салып, җылы урында 2 сәгать төнәтәләр, сөзеп, ашарга ярты сәгать кала яки ашаганнан соң 1 сәгать үткәч 1 әр стакан эчәләр. Валерианада коронар тамырларны киңәйтә һәм йөрәкнең нерв-мускул аппараты эшчәнлеген җайлый торган матдәләр бар. 1 аш кашыгы вакланган валериана тамырын ярты стакан кайнатып суытылган суга салалар да, тәүлек буе төнәтәләр, өчкә бүлеп, көн буена эчеп бетерәләр. Валериана препаратлары белән дәва курсын 3 айдан арттырырга ярамый.

17 сентябрь (якшәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 2 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 8.30 сәгатьтә калка, 19.16 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.41 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Йөрәккә дәва (2)

Бөтнектәге ментол авыртуны басу, спазмнарны бетерү, коронар тамырларны киңәйтү, йогышсызландыру үзлекләренә ия. 1 аш кашыгы бөтнек яфрагын 1 стакан кайнар суда 20 минут төнәтеп, сөзәләр, ач карынга, иртәнге ашка ярты сәгать кала, эчәләр. Мелисса тынычландыра, йөрәк кыскарулары ритмын җайга сала, йөрәк мускулын ныгыта. 2 аш кашыгы мелисса үләнен 1 стакан кайнар суга салып, кайнап торган сулы кәстрүлдә 15 минут тоталар, суытып, сөзәләр, көненә 3 тапкыр, ашаганнан соң 1 сәгать үткәч, өчтән берешәр стакан эчәләр. Дәва курсы – 3-4 атна. Кан басымы түбән булганда, болай дәваланмау хәерлерәк.

18 сентябрь (дүшәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 3 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 9.51 сәгатьтә калка, 19.22 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.36 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп тупланунын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Йөрәккә дәва (3)

Сукыр кычыткан йөрәк ритмын әкренәйтә, кан басымын төшерә, невроз, стенокар-

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карап

дия, кардиосклероз, миокардитны дәвалый. 2 десерт кашыгы үләнне 1 стакан кайнар суга салып, кайнап торган сулы кәстрүлдә 15 минут тоталар, суытып, сөзәләр, көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, яртышар стакан эчәләр. Гипотония, брадикардия булганда, сукыр кычыткан белән дәваланырга ярамый. Һиндыба (цикорий) йөрәк эшчәнлеген яхшырта, йөрәк кыскарулары ритмын әкренәйтә. 1-2 чәй кашыгы үләнне 1 стакан кайнар суда 20 минут төнәтәләр, сөзеп, көненә 2-3 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, яртышар стакан эчәләр. 1 чәй кашыгы вакланган тамырны 1 стакан кайнар суга салып, 5 минут пешерәләр, 1 сәгать төнәткәч, сөзеп, бал кушып, көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, яртышар стакан эчәләр.

19 сентябрь (сишәмбе). ***Рабигуль әүвәл аеның 4 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 11.16 сәгатьтә калка, 19.32 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.31 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

20 сентябрь (чәршәмбе). ***Рабигуль әүвәл аеның 5 нче көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 12.47 сәгатьтә калка, 19.47 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.27 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

21 сентябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигуль әүвәл аеның 6 нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 14.18 сәгатьтә калка, 20.13 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.23 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

22 сентябрь (җомга). ***Рабигуль әүвәл аеның 7 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 15.39 сәгатьтә калка, 20.57 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 12.18 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне упкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

Эремчекле банан катламасы

5 аш кашыгы солы ярмасы, 300 грамм майсыз эремчек, 2 банан, 1 йомырка, тәменчә шикәр кирәк. Солы ярмасын блендерда ваклап, шуңа эремчек, йомырка, шикәр кушып, камыр басалар, икегә бүлеп, җәяләр, берәр банан куеп, рулет итеп төрәләр, пергамент кәгазе җәелгән табага күчереп, 180 градуслы газ мичендә 20-30 минут пешерәләр.

Нурулла хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН:

«Зина кылуга җайлашса, күпләр өйләнешми»

Гаилә кору – һәрбер кешенең тормышындагы иң мөһим этапларның берсе, ләкин гаилә коруга Аллаһы Тәгалә билгеләгәнне бозмыйча килү мөһим. Ә булачак ирең белән ничек танышырга соң? Үбешергә, Интернет аша аралашырга ярыймы? «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы Нурулла хәзрәт Зиннәтуллин әлеге сорауларга җавап бирә.

– Ислам дине кануннары буенча егет белән кыз ничек танышырга тиеш?

– Төрле ысуллар белән танышырга була. Идеаль очракта егетне яки кызны әти-әнисе өйләндерергә тиеш, ягъни әти-әнисе баласының үсеп җиткәнлеген аңлап, танышлары арасыннан аларга егет яки кыз эзләп таба да таныштыра. «Әйдә, мин сиңа өйләнәм яки кияүгә чыгам», – дип, үзләре танышсалар да була. Бөтен ысуллар да рөхсәт ителә. Иң мөһиме – өйләнү нияте барлыгы турында әти-әни белән сөйләшү. Ләкин кыз белән егет арасында бернинди дә кагылулар, ирекле темаларга сөйләшеп утыру (мәхәббәт, тегеләй-болай), Интернет аша язышулар булырга тиеш түгел. Әти-әнигә белдермичә андый темаларга сөйләшеп, язышып утыру тыела, чөнки яшьләр чамалап бетерми, хисләргә бирелеп, үзләренә туры килмәгән кешене сайларга мөмкин.

– Кыз кеше беренче булып очрашырга теләк белдерә аламы?

– Ул үзе беренче килеп дәшәргә дә мөмкин яки кеше аша да теләген белдерсә була. Гомумән, ислам диненда «очрашу» дигән сүз юк, ул – дөньяви. Диндә ул «хитба», ягъни «ярәшү, өйләнешү өчен көрәшү, аралашу» дип атала. Әлеге тәкъдимне ир кеше ясаса да, кыз кеше ясаса да, кызның әти-әнисе белеп торырга тиеш.

– Бергә калырга ярыймы?

– Егет белән кыз йөрсәләр дә, икәүдән-икәү кала алмый. Аларга җәмәгать урыннарында яки кызның әти-әнисе, туганнары янында гына очрашу мөмкин. Гомумән, очрашып йөрү бернәрсә дә бирми, чөнки кайдадыр йолдызлар санап йөреп, кафеларда утырып, бер-береңнең кем икәнлеген белеп булмый. Кеше турында башка кешеләрдән сорап белешәләр. Мәсәлән, сиңа кыз ошады икән, син шул кызның танышларыннан аның холкы, гаиләсе, яшәү рәвешләре турында белешсәң. Кеше турында шулай белешәләр, бервакытта да үзеннән сорамыйлар. «Син яхшы кешеме?» – дип сорасаң, гел «Әйе», – дигән җавапны ишетәсең, беркем дә: «Мин – җүләр, тиле, псих», – дип әйтми.

– Вакыт ягыннан күпме очрашырга була?

– Ярәшү (хитба) бер елдан артык булырга тиеш түгел, ягъни шул вакытта бер-берләрен өйрәнәләр, никахка, туйга әзерләнә башлыйлар. Озак очрашуларның файдасы юк. Очрашу бары тик тышкы кыяфәтне, сөйләшү, үз-үзен тоту манерасын карар өчен генә кирәк. Калганын кешеләрдән белешеп, бер-береңнән «Син оялчанмы?», «Ничә бала кирәк?» дип утыру – юк-бар, бер нәрсә дә бирми торган сораулар. Бүгенге көндә бер-беребезне өйрәнәбез дип, 6-5 ел буена очрашып йөриләр, ә өйләнешкәннән соң «ярты бала» табалар да, 1 ел да тора алмыйча аерылышалар. Ни бу? Алар бер-берсен белмәгән, өйрәнмәгән, үзләренә ни кирәген белми. Ул бер-береңбелән йөрешү – зина кылу, үбешү, кулга-кул тотынып йөрү өчен генә кирәк, ә калганы өчен файдасы юк.

– Өйләнешер алдыннан егет белән кыз ни турында сөйләшергә тиеш?

– Мәҗбүри темалар юк. Дини яктан караганда дине, белеме, холкы турында белү мөһим, ләкин, сөйләшеп, кешенең дини белемен белеп булса да, холкын белеп булмый. Сөйләшкәндә кеше «маска» киеп сөйләшә, матур итеп кылана, дөрес сүзләр куллана.

– Элеккегеләр турында сорашсаң буламы? Кайбер чыганакларда «хөкем ителү, баласы булу-булмау турында гына сорарга ярый» диелә.

– Әлбәттә, сорарга ярый. Ләкин кеше турында кызыксындырган сорауларны каршына килеп, күзенә терәп бирмиләр. Кеше белән очрашырга килгәнче үк билгеле бер мәгълүмат белән килергә кирәк. Урамда, мәсәлән, егет кешенең кызның матур к...тләрен, имиләрен күргәч, «башы китә», ул баш белән уйламый, «башка» әйбер белән уйлый. Һәм ул кыз нәрсә генә сөйләсә дә, «мин 2 тапкыр төрмәдә утырдым, минем 10 балам бар» дисә дә, аңа барыбер, чөнки «башка әйбер» кирәк. Шуңа күрә иң беренче – мәгълүмат алалар, белмәгән кеше янына бармыйлар, бары тик белгән кеше белән генә очрашалар. Ул вакытта инде кирәкмәгән сораулар да биреп утырмыйсың. Очрашу вакытында буй-сынын, тотышын, әдәбен генә белергә кала. Шулар килешсә, өйләнергә яки кияүгә чыгарга була.

– Интернет аша танышырга, аралашырга, фотолар җибәрешергә ярыймы?

– Бернәрсә дә ярамый, бу – тыелган. Интернетта син бернәрсә дә белмичә танышасың. Ялганга килеп эләгүең бар, чөнки бер кеше дә үзе турында бөтен дөресен әйтеп бетерми. Мәсәлән, егет кеше башта кызны үзенә гашыйк итә һәм соңыннан гына «мин 5 кеше үтергән идем» дип әйтеп куя, ә кызның «башы киткән», «ярар-ярар, начар кешеләр булгандыр» диләр дә, өйләнешеп куялар. Шуңа күрә андый аралашулар кирәкми, башта кеше турында белергә кирәк.

– Бала табарга теләмәгән парларның өйләнешүе дөресме?

– Бала табудан баш тарту гөнаһ булып санала, бу – кешенең табигатенә каршы килү. Шуңа күрә ир кеше белән хатын-кыз мондый фикергә килгән икән, алар гөнаһлы булып санала. Мин аларның өйләнешүләре дөрес түгел дип әйтмим, никахлары дөрес була, ләкин никахларының дөрес максаты дөрес түгел. Алар, әлбәттә, балалары булмаганлыкка 100 тапкыр үкенәчәк, ләкин «яшьлек белән» башлары эшләми әле.

– Бөтенләй өйләнешмәскә, гаилә кормаска ярыймы?

– Өйләнешергә, кияүгә чыгарга теләмәгән кызлар-егетләр, гадәттә, зина кылып йөри. Алар бит болай гына йөрми, хәзерге заман шундый бит. Күпчелек кыз адым саен «биргәндә», «йөргәндә», билгеле, калганнар да «нәрсәгә миңа өйләнергә», «нигә кияүгә чыгарга кирәк соң», ди. Шуңа күрә андый фикер белән кияүгә чыкмау яки өйләнмәү дөрес түгел. Өйләнешү ике сәбәп буенча туа: зина кылмау һәм балалар алып кайту өчен. Әгәр дә зина, гөнаһ кылып йөрмәсәң, гомумән, җенси тормыш кызыксындырмаса, яки холкың начар булса (мәсәлән, ир-ат өйләнгәч, хатынын кыйнаса, яки хатын-кызның холкы начар булып, ире газапланса) өйләнмәска карар кылып була.

«Егет белән кыз арасында дуслык мөнәсәбәтләре булырга мөмкин түгел. Андый очрашулар, йөрешүләр катгый тыелган. Егет белән кыз икәү генә калса, өченчесе шайтан була», дигән Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.).

Камилә БИЛАЛОВА.

Мәдәни җомга
15 сентябрь
№36, 2023

● Екатеринбургтагы сәүдәгәр Агафуровлар йортында татар педагогика техникумы урнашкан була. 1990 елгы фото.

● Красноуфимск каласындагы ике сыйныфлы татар-башкорт мәктәбе. XX гасыр башы фотосы.

Екатеринбург өязендәге татар мәктәпләре

Мәктәпләр инструкторы В.Исаев нәкъ Октябрь түнтәрешеннән соң ул чакта бик популяр булган «Отечественные записки» журналында «Екатеринбург өязендәге татар-башкорт мәктәпләре» дигән мәкалә бастырып чыгара. Әлеге язманың зур өлешен бер гасыр узгач, «Гражданская война в России и мусульмане» атлы җыентыкта да (М., 2014. 171-172 нче битләр) кабатлап нәшер итәләр. Инспектор менә болай яза:

«Мин 1919 елның гыйнвар ахыры-февраль башында Екатеринбург өязендәге татар-башкорт мәктәпләрен тикшердем. Үткән 1917-1918 елда өяз управасында 23 мәктәп исәпләнгән, хәзер шулардан 19 ы калган...

Башкорт краендагы бөтен укыту системасын тамырдан үзгәртү зарур. Инкыйлабтан соң мөселманнарга гомумән үз хокукларын яклау һәм, аерым алганда, мәктәп эшен яхшырту мөмкинлеге бирелгәч, тиз арада корылтайлар үткәрелде. Әлеге съездларда бөтен Россия мөселманнары башлангыч гомуми белем бирү мәктәпләре, аларда уку вакыты, укыту теле һәм программалар турында билгеле бер килешүгә килде.

Бөтенроссия беренче һәм икенче мөселман съездларының төп кагыйдәнамәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) башлангыч мөселман мәктәпләрендә укыту 6 ел булырга;

2) бөтен мөселман мәктәпләрендә укыту ана телендә башкарылырга;

3) рус теле башлангыч мөселман мәктәпләре программасына аерым предмет буларак дүртенче уку елыннан кертелергә тиеш.

Әлеге гомуми кагыйдәнамәләр хәзер Урал аръягындагы барлык мөселман мәктәпләрендә дә кабул ителгән программаның нигезен тәшкил итә. 2 февральдә Кояш авылында үткән өяз башкорт мәктәпләре мөгаллимнәре корылтае да әлеге программаны яклап чыккан. Программага: укырга, язарга өйрәтү, арифметика, тарих, география һәм табигать белеме керә, дүртенче елдан кертелә башлаган рус теленә атнасына 9 дәрес бүленә».

Әмма, инспектор әйтүенчә, дәреслекләр җитми, мөселман мәктәпләрендәге мөгаллимнәрнең дөньяви фәннәр буенча белемнәре бик зәгыйфь. Әлеге мөгаллимнәрнең күпчелеге рөшдияләрдә генә укыган. Бу мәктәпләр исә Халык мәгарифе министрлыгының ике класслы училищеларына гына тәңгәл, аларның да күпчелегендә белем бирү тиешле дәрәҗәдә оештырылмаган булган.

Инспектор янә дәвам итә: «Киләсе 1919-1920 уку елыннан өяздәге бөтен татар-башкорт мәктәпләрен алдарак аталган кагыйдәнамәләргә туры китереп 6 еллык милли гомуми белем бирү мәктәпләре итеп үзгәртергә һәм мәктәпләр челтәренә кертергә кирәк. Әмма татар-башкорт мәктәпләре аларда укымышлы мөгаллимнәр белем бирсә генә тиешле югарылыкта эшли алачак. Әлегә исә Екатеринбург өязендәге мөселман мәктәпләрендәге кадрларның күпчелеге куелган бурычларны үтәрлек дәрәҗәдә аң-белемле түгел, алар моны үзләре дә аңлый...»

Совет власте урнашкач, әлеге хилафлыкны бетерү максатыннан, 1919 елның 10 октябрендә Екатеринбургта махсус Мөселман (соңрак татар-башкорт) педагогика техникумы ачыла. Ерак Екатеринбургта түгел, хәтта Татарстан белән Башкортстанда да Өфе, Бәләбәй, Бөре, Мамадыш, Чистай, Минзәлә, Бөгелмә каларында 1920-1950 елларда татар теле һәм әдәбиятын укыту буенча аерым педагогия техникумнары гөрләп эшли иде әле. Ни кызганыч, хәзер фәннәрне татар һәм башкорт телләрендә укыта торган мәктәпләр дә санаулы гына калып бара.

«Башинформ».
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА
тәрҗемәсе.

● Екатеринбург-Свердловск шәһәренең Ленин урамындагы 16 нчы йортта 1920 елларда 4 нче татар-башкорт мәктәбе эшли.

● Екатеринбург-Свердловск. Менә бу Шейнкман урамындагы 14 нче йорт янәшәсендә 1920 елларда татар-башкорт җидееллык мәктәбе урнашкан була.

Кайда арта, кайда кими

Быел гыйнвар-июль айларында РФ һәм КХР арасында товар әйләнеше 36,5 процентка арткан һәм 134,1 миллиард долларга җиткән. Шул вакыт эчендә Кытай Россиягә 62,545 миллиард долларлык товар керткән, 2022 елның шул чоры белән чагыштырганда үсеш 73,4 процент тәшкил иткән. Россиядән Кытайга экспорт 15,1 процентка арткан һәм 71,559 миллиард долларлык булган. Шул ук вакыт аралыгында КХР белән АКШ арасында товар әйләнеше 15,4 процентка кимегән һәм 381 миллиард доллар тәшкил иткән. Быелның җиде аенда Кытайдан Америкага экспорт 18,6 процентка кимегән һәм 281,655 миллиард долларлык булган. АКШ Кытайга 99,859 миллиард долларлык товар җибәргән, бу узган елның шул чорындагыдан 4,7 процентка кимрәк. Сизелерлек үсешкә карамастан, РФ белән КХР арасында товар әйләнешендәге аерма АКШ белән Кытай арасындагыдан өч тапкырга кимрәк әле. Россиянең Кытайга экспортының 75 процентын нефть һәм газ, тагын 20 процентын үзагач һәм целлюлоза, металл, авыл хуҗалыгы продукциясе һәм химик ашламалар тәшкил итә. Америка Кытайга исә авыл хуҗалыгы продукциясе (ашлык, соя, ит, чикләвек), нефть һәм газ, авиация һәм автомобиль техникасы, технологик продукция (электроника, компьютерлар, ярымүткәргечләр, микропроцессорлар), химия продукциясе, медицина һәм фән җиһазлары, фармацевтика препаратлары сата.

(“Лента.ру”).

Башта бөҗәкләр юкка чыга...

Галимнәрне бөҗәкләр санының күпкә кимүе борчуга салган, димәк, тиздән кош һәм хайваннар популяциясе дә кимеячәк, аннары чират кешенең үзенә барып җитәчәк... Германиядәге “Крефельд энтомология җәмгыяте” Көнбатыш Европаның 100 табигать тыюлыгында күзәтүләр үткәргән һәм бөҗәкләр санының кимүен раслаган. Мәсәлән, бер тыюлыктагы махсус тозакка 2013 елда 1989 елдагыга караганда 80 процентка кимрәк бөҗәк эләккән. Башка урыннарда үткәрелгән тикшеренүләр дә бу коточкыч тенденцияне дәлилли. Бөҗәкләрнең күпләп кырылуында көчле инсектицидлар һәм пестицидлар гаепле. Агулы химикатлар аркасында умарта кортлары колонияләре саны да 30 процентка кимегән. Кайбер аеруча сизгер бөҗәкләр исә кәрәзле телефон элемтәсе һәм чыбыксыз интернет тәэсиреннән юкка чыга, бу бигрәк тә нурланыш тарата торган каланчалардан 500 метрлы радиуста күзәтелә. Неоникотиноидлы инсектицидлар тәэсирендә бөҗәкләрнең баш мие күзәнәкләре эшләүдән туктый, шул аларны параличлый һәм үтерә. 2000 елга кадәр әлеге матдә турында беркем дә белмәгән, хәзер исә ул авыл хуҗалыгында иң популяр агу санала. Ә бит бу матдә хәтта рәсми сынау да үтмәгән икән. Алай гына да түгел, хәзер неоникотиноидлар хәтта балда да табылган. 2013 елдан бу пестицидны куллануга чикләүләр кертелгән, тик әле хәзер дә Европа кырларыннан җыелган балда шул агу булуы ачыкланган – чөнки туфракка тирәнгә үк кереп калган. Ул кешедә неврология авырулары китереп чыгарырга сәләтле икән. Хәзер аны бөтенләй тыярга җыеналар, тик Американың “Монсанто” һәм “Дюпон”, Германиянең “Байер” һәм “БАСФ” кебек куәтле химия концерннары тиз генә бирешергә җыенмый.

(“Daily Mail”).

Яшьтән белеп була

